ПИОНЕР КАЛӘМЕ

МАРТ 1940 № 3

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

ЛЕНИН—СТАЛИН ЭШЕ ӨЧЕН КӨРӘШКӘ ХӘЗЕР БУЛ!

ПИОНЕР КАЛӘМЕ

БАЛАЛАР ӨЧЕН ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН АЙЛЫК ӘДӘБИ ЖУРНАЛ. ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ ОРГАНЫ.

БУ НОМЕРДА:

Лениннең һәм Сталинның турылыклы көрәштәше Вячеслав Михайлович Молотовка ВКП(б) Үзәк Комитеты котлавы 2
СССР Верховный Советы Президиумы указы 2
Вячеслав Михайлович Молотов 3
Дус һәм иптәш (Н. С. Чирков истәлеге) 9
Кадерле кунак (О. Тихомирнова истәлеге) 9
Онтылмаслык очрашулар (Әнвәр Фәйзуллин һәм Лев. Безыменский истәлекләре) 11
Алмас абый (Кави Нәҗми шигыре, П. Новичков рәсемнәре) 14
Безнең байрак (Г. Камалов шигыре) 17
Кызыл йолдызлылар (Шамиль Латыйпов шигыре) 17
Чаңгыда (Д. Нәкыйп шигыре) 17
Әниләр һәм апалар бәйрәме 18
Баһадирлар(М. Сөндекле шигыре, Г. Арсланов рәсемнәре) 19
Париж коммунасы 24
Калкукырда кар беткәч (Мирсәй Әмир хикәясе, П. Новичков рәсемнәре) 25
Тимерчеләр цехында (Г. Халик Садрый) 30
Жюль Верн (Хәмит Кави мәкаләсе) 32
Рәсемнәр.

Журналның тышлыгында: Москва Дәүләт Консерваториясенең композиторы В. Я. Шебалинның улы, талантлы яшь музыкант Митя Шебалин. Иптәш Сталинның тууына 60 ел тулуга карата ул музыка язды. **Рәсемдә:** Митя Шебалин үзенең әтисе белән рояль янында. Фото— А. Сизиков (ТАСС фотоклишесе). **Тышлыкның өченче битендә:** күңелле ял.

Редакциянең адресы: Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. Матбугат йорты (2 нче кат, 5 нче бүлмә). Телефон № 18—78.

МАРТ 1940 № 3

Лениннеҥ һәм Сталинныҥ турылыклы көрәштәше Вячеслав Михайлович Молотовка

Большевиклар партиясенеҥ Үзәк Комитеты сине, Лениннеҥ һәм Сталинныҥ турылыклы көрәштәшен, Совет хөкүмәте җитәкчесен — синеҥ илле еллыгыҥ көнендә кайнар рәвештә котлый.

Бөтен аҥлы тормышыҥ буена син большевиклар партиясенеҥ күренекле эшлеклесе һәм юлбашчысы сыйфатында эшчеләр сыйнфы эшенә, коммунизм эшенә хезмәт итәсеҥ. 1905—1907 нче еллардагы революция җиҥелгәннән соҥ кара реакция елларында, эшчеләр хәрәкәтенеҥ күтәрелеше елларында, „Звезда“ һәм „Правда“ чорында, бөтен дөнья күләмендәге беренче империалистик сугыш утында—син һәр вакыт большевизм байрагын югары тоттыҥ, илебездә пролетариат диктатурасы өчен армыйталмый көрәштеҥ.

Петроград Хәрби-Революцион Комитет члены буларак, син 1917 нче елныҥ октябрендә зур революцион-большевистик эш алып бардыҥ. Донбассныҥ, Украинаныҥ, Москваныҥ партия оешмалары җитәкчесе сыйфатында, ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре сыйфатында эшләвеҥ белән, Совет хөкүмәте башлыгы постында озак еллык данлыклы эшеҥ белән син партиянеҥ һәм Советлар Союзы хезмәт ияләренеҥ кайнар мәхәббәтен һәм гаять зур ихтирамын казандыҥ.

Большевиклар партиясенеҥ күренекле юлбашчыларыннан берсе буларак, социалистик экономиканы һәм яҥа, коммунистик культураны гаять зур оештыручы буларак, син үзеҥдә Ленин—Сталин типындагы политик эшлекленеҥ иҥ яхшы сыйфатларын гәүдәләндердеҥ. Син марксизм-ленинизм идеяләре өчен һәр вакыт эзлекле көрәш алып бардыҥ һәм алып барасыҥ, партиянеҥ һәм совет халкыныҥ дошманнарына каршы, троцкийчыларга, зиновьевчыларга, бухаринчыларга һәм буржуазиянеҥ башка агентларына каршы партиянеҥ юлын тайпылышсыз сакладыҥ.

Социализм иле үзенеҥ уҥышлары һәм җиҥүләре өчен күп яктан синеҥ энергияҥә, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе постында синеҥ армый-талмый эшләвеҥә бурычлы. Партия һәм ил алдында телдән һәм матбугатта ясаган чыгышларыңда син коммунистик җәмгыять төзү буенча бөек эшнеҥ гаять зур тәҗрибәсен туплыйсыҥ.

Сиҥа, кадерле дустыбыз һәм иптәшебез, чын күҥелдән озак еллар буена сәламәтлек һәм партиябез файдасына, Ватаныбыз файдасына, коммунизм файдасына киләчәктә дә нәтиҗәле эш телибез.

БӨТЕНСОЮЗ КОММУНИСТЛАР (большевиклар) ПАРТИЯСЕ ҮЗӘК КОМИТЕТЫ.

*****

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ

УКАЗЫ

СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш Вячеслав Михайлович Молотовны Ленин ордены белән бүләкләү турында

Большевиклар партиясен оештыру, Совет дәүләтен төзү һәм ныгыту эшендәге күренекле хезмәтләре өчен СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш Вячеслав Михайлович **Молотовны**, аныҥ 50 еллыгы көнендә,—**Ленин** ордены белән бүләкләргә.

СССР Верхоный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 8 март, 1940 ел.

ВЯЧЕСЛАВ МИХАЙЛОВИЧ МОЛОТОВ

Лениннең һәм Сталинның турылыклы көрәштәше, большевиклар партиясенең күрнекле эшлеклесе һәм юлбашчысы, Совет хөкүмәте башлыгы Вячеслав Михайлович Молотовка илле яш тулуны большевиклар партиясе, социализм иленең барлык хезмәт ияләре зур күтәренкелек белән бәйрәм итте.

Иптәш Молотов үзенең бөтен аңлы тормышын яш вакыттан ук эшчеләр сыйнфын азат итүгә, социализм тантанасы эшенә багышлый. Царизм вактында ук инде ул Ленин—Сталин партиясе байрагын югары күтәреп, царизмны бәреп төшерү өчен, революциянең җиңүе өчен армый-талмый көрәшә. Партиябезнең күрнекле юлбашчыларыннан берсе буларак, иптәш Молотов 1917 нче елның октябрендә дә зур революцион-большевистик эш алып бара. Совет власте урнаштырылганнан соң ул совет һәм партиянең җаваплы эшләрендә эшли.

СССР Совнаркомы председателе булып билгеләнүе уңае белән иптәш Молотов болай диде:

„Мин большевиклар партиясендә үстем һәм күп еллык өзлексез эш белән аңа бәйләнгәнмен. Коммунист сыйфатында миндә, эштә Ленин шәкерте булудан да зуррак теләк юк һәм булуы да мөмкин түгел... Соңгы еллар эчендә миңа, Үзәк Комитет секретаре сыйфатында, Лениннең иң яхшы шәкертенең турыдан-туры җитәкчелеге астында, иптәш Сталинның турыдан-туры җитәкчелеге астында большевистик эш мәктәбен үтәргә туры килде. Мин моның белән горурланам“.

Совет хөкүмәте башлыгы постында озак еллык данлыклы эше белән иптәш Молотов партиянең һәм халыкның кайнар мәхәббәтен һәм гаять зур ихтирамын казанды. Чит Ил Эшләре Халык Комиссары постында буларак, большевиклар партиясенең зирәк политикасын һәм бөек Сталинның күрсәтмәләрен гадәттән тыш осталык белән үткәреп, иптәш Молотов Ватаныбызны яңадан яңа уңышларга ирештерә.

Менә шуңа күрә дә бөтен совет халкы һәм совет балалары Вячеслав Михайлович Молотовның исмен гаять тирән җылылык белән, горурлык хисе белән атыйлар һәм Ленин—Сталин типындагы данлыклы большевикның тормыш юлын өйрәнәләр.

Вячеслав Михайлович Молотов (Скрябин) 1890 нчы елның 9 нчы мартында Вятка губернасының Кукарка бистәсендә (хәзерге Киров өлкәсе, Советск шәһәре) хезмәткәр семьясендә туа.

Әтисе, Михайл Прохорович Скрябин, башта аны Нолинскидагы (хәзер Молотовск) училищегә укырга бирә. Тәрәзә янында, икенче партага утырган бу яңа укучы мәктәпкә килеп керүенең беренче көннәрендә үк үзенең тырышлыгы, укуны яратуы, дисциплиналы булуы белән игтибар казана. Мәктәптә аны яратып, Вячик дип йөртәләр. „Барлык фәннәрдән дә бик яхшы өлгергән Вячик, арифметика дәресләрен аеруча нык ярата иде“,—ди укытучы Кореневский.

Вячикнең дәфтәрләре һәр вакыт чиста, тапсыз булалар. Аның дәфтәрләрен укытучылар рәхәтләнеп карый торган булганнар.

Бер вакыт әтисе улының ничек укыганын белергә теләп, мәктәпкә килгәч, укытучы Кореневский аңа горурланып:

— Башка балаларның да Вячик укытан кебек үк яхшы укуларын теләр идем!—дип җавап бирә.

Яхшы укыганы өчен Вячик „Похвальный лист“ белән бүләкләнә.

Иптәш Молотов утырып укыган парта хәзер дә саклана әле. Совет балалары, Вячик шикелле, тырышып укырга, дәрес сәгатләрен аның партасында уздырырга телиләр һәм шул шатлыкка ирешү өчен иң алдынгы укучы булырга ярышалар. Молотовск шәһәрендә хәзер иң яхшы класс (VI нчы „А“ классы) Вячик укыган бүлмәдә укый. Шул классның иң яхшы отличник укучыларыннан Викторина Лялина белән Таня Леушина Вячик утырган партада утыралар. Нинди бәхетле балалар!

1902 нче елда Молотов Казанга күчә һәм Булакның сул ягына салынган элекке 1 нче реальный училищегә укырга керә. Биредә дә ул иң алдынгы укучыларның берсе була. Һәр көн диярлек ул үзе белән бергә укучы балаларга нинди дә булса авыр мәсьәләне аңлата, дәресне яхшы үзләштерергә булыша.

Молотовның революцион хәрәкәткә аңлы рәвештә катнашып китүе дә Казан шәһәреннән башлана. Укучы Вячик, мәктәптәге каты режимга да карамастан, Маркс һәм Ленин китапларын табып укый, партиянең программасын өйрәнә. Царизмга каршы көрәшүне үзенә бурыч итеп куйган һәм политик белем белән коралланган алдынгы укучы Вячик озакламый Казанда революцион-укучы яшьләрнең җитәкчесе булып әверелә. Большевиклар партиясенең Казан комитеты тапшыруы буенча ул революцион листовкалар бастырып тарата, уку йортларында үткәрелгән митингларга катнаша, түгәрәкләр оештыра.

1906 нчы елда Молотов Казанда большевиклар партиясенә керә. Ул елларда 16 яшьлек Молотов хәзерге Свердлов урамында (элекке Георгиевский) 11 нче номерлы йортның икенче катында тора. Бу йорт алдында һәр вакыт жандарм йөреп торган. Шунлыктан Вячеслав Михайлович күбрәк вактын якын дусты Виктор Тихомирнов янында (үзенә күрше бакча эчендәге йортта) уздырган. Шунда яшь большевиклар еш җыелганнар, башка шәһәрләрдәге революцион укучыларга шунда хатлар язганнар, революцион эш алып барганнар.

Молотов Кабан күле буендагы Учительская семинариядә дә революцион түгәрәк белән җитәкчелек иткән. Андагы укучылар аны һәр килүендә яратып каршы алганнар. Бер көнне полиция отряды семинарияне чолгап ала. Коточкыч погром ясала. Күп кенә укучылар мәктәптән чыгарылалар. Молотов тәкъдиме буенча мәктәптә ачлык игълан ителә һәм укучылар җиңәләр: чыгарылганнар кире кайтарылалар.

Зур революцион эш алып баруы белән бергә, Молотов яхшы укырга да, артта калган укучыларга булышырга да, скрипкада уйнарга да, күңелле итеп җырларга да вакыт тапкан.

Вячеслав Михайлович Молотов революцион эшен киңәйткәннән-киңәйтә бара. Ул укучылар арасында эш алып бару белән бергә, төрмәләргә ябылган һәм сөргенгә җибәрелгән рево-

В. М. МОЛОТОВ.

Худ. Г. Я. Поляков рәсме (Казан).

люционерларга акча җыюны оештыра, большевистик әдәбият таратуда ярдәм итә, эшчеләр арасында пропаганда эше алып бара.

1909 нчы елның апрелендә жандарм управлениесе Молотов квартирасында тентү ясарга боерык бирә. Шул ук айда иптәш Молотов кулга алынып, Вологда губернасына ике елга сөргенгә җибәрелә.

Сөргендә вакытта В. М. Молотов башта Тотьма һәм Сольвычегодск шәһәрләрендә, ә аннан соң Вологда шәһәрендә була. Вологдада ул тимер юл эшчеләре арасында яшрен рәвештә партия эше алып бара. Вологда шәһәрендә Молотов төзегән большевиклар оешмасы 1910—1911 нче елларда үзенең эшен көчәйтә һәм Ленин юлын нык үткәрә. Шул чорда ук иптәш Молотов меньшевикларга каршы рәхимсез көрәш алып бара.

Сөргендә чагында да В. М. Молотов марксизм классиклары әсәрләрен зур игтибар белән өйрәнүен дәвам иттерә. Вологданың һәм Вятканың жандарм идарәләре үзләренең агентлык донесениеләрендә Молотов „социал-демократларның программасын һәм әдәбиатын бик яхшы белүе белән башкалардан аерыла“, „җидди оештыручы булып санала“,—дип күрсәтәләр.

Сөргендә булу срогын тутырганнан соң, 1911 нче елның июнендә, иптәш Молотов Петербургка бара һәм анда Политехника институтына укырга керә. Биредә ул студентлар арасында революцион эш алып бара һәм эшчеләрнең берничә түгәрәгендә эшли.

1912 нче елда В. М. Молотов большевистик „Звезда“ газетасында эшли башлый һәм „Правда“ газетасын тудыру эшенә актив катнаша. Шул ук елда „Правда“ редакциясе составына керә. „Правда“ да ул А. Рябин, В. Михайлов, А. Званов псевдонимнары астында үзенең мәкаләләрен бастыра.

Иптәш Молотовның иптәш Сталин белән беренче тапкыр очрашуы да шул ук елда була. „Правда“ редакциясенең секретаре һәм җитәкчеләренең берсе буларак, иптәш Молотов большевикларның чит илдәге үзәге белән һәм турыдан-туры В. И. Ленинненң үзе белән язышу алып бара.

Полициянең эзәрлекләве аркасында В. М. Молотов 1912 нче елның ахрында подпольегә күчә. Бу чорда ул большевикларның Петербург комитеты члены була.

Иптәш Молотов революцион эш алып баруы өчен 1912 нче ел белән 1914 нче ел арасында өч тапкыр кулга алына. Аңа зур шәһәрләрдә тору тыела. Ләкин чыныккан революционер Петербургка барыбер кайта, большевикларның Петербург оешмасында һәм „Правда“ да яшрен рәвештә партия эшен дәвам иттерә, Ленин, Сталин күрсәтмәләрен тормышка ашыру өчен чиксез энергия белән көрәшә.

1914 нче елдагы империалистик сугыш башланганда В. М. Молотов Петербургта була. Сугыш турындагы мәсьәләдә ул Ленин карашында тора. Ул бу сугышның империалистик талаучылар файдасы өчен башланганын фаш итә.

Озакламыйча иптәш Молотов Москвага күчә һәм анда сугыш башланганда патша охранкасы тарафыннан таратылган большевистик оешманы аякка бастыра. Москвада ул эшчеләр арасында эшли, партия сафларын провокаторлардан чистарта, империалистик сугышны гражданнар сугышына әйләндерү өчен көрәшә.

1915 нче елның язында Москва большевикларының гомуми шәһәр конференциясен чакыру хәзерләнә. Ләкин оешмага үтеп кергән провокаторлар доносы буенча иптәш Молотов июнь аенда кулга алына һәм этап белән Иркутск губернасына (Манзурка авылына) 3 елга сөргенгә җибәрелә. 1916 нчы елның маенда ул сөргеннән качып, Петроградка кайта һәм анда яшрен рәвештә революцион эш алып бара. Шушы ук елның көзендә иптәш Молотов большевиклар Үзәк Комитетының Россия Бюросы составына кертелә һәм бу бюрога җитәкчелек итә. Бу чорда сугышка һәм эшчеләр хәрәкәтенең көндәлек бурычларына багышлап чыгарылган күп кенә сугышчан прокламацияләр иптәш Молотовның катнашы белән чыгарылалар.

Иптәш Сталин зур вакыйга дип күрсәтеп үткән ул чордагы бердән-бер легаль большевистик журнал булган „Вопросы страхования“ журналы да В. М. Молотовның катнашуы белән чыгарыла.

1917 нче елгы февраль революциясе чорында иптәш Молотов большевикларның Петроград комитеты члены, Петроград советының Башкарма Комитеты члены була. Шул ук елда ул „Правда“ газетасын торгызу һәм чыгару эшенә җитәкчелек итә һәм иптәш Сталин сөргеннән кайтканга кадәр анда төп редакторларның берсе булып эшли.

В. М. Молотов партиянең апрель конференциясендә һәм партиянең VI нчы съездында актив рәвештә катнаша. Съездда сөйләгән речендә ул Ленин һәм Сталин иптәшләрнең юлын яклый.

Октябрь штурмы көннәрендә иптәш Молотов турыдан-туры Ленин һәм Сталин җитәкчелеге астында эшләүче большевикларның иң актив җитәкчеләреннән берсе була. Ул Бөек Октябрь көннәрендә восстание белән җитәкчелек иткән Хәрби революцион комитетның члены.

1918 нче елның башында иптәш Молотов Төньяк районның халык хуҗалыгы Советы председателе итеп күтәрелә. Ул чагында бу районга җиде губерна (шул исәптән Петроград губернасы да) керә иде.

1919 нчы елның җәендә В. М. Молотов Волга буе губерналарына партиянең һәм Совет хөкүмәтенең вәкиле итеп билгеләнә. Күп кенә шәһәрләрдә һәм авылларда булып зур-зур эшләр башкара. Шул ук елның азагында ул Нижегородск губерна башкарма комитетының председателе булып эшли. 1920 нче елның сентябрендә большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты аны Донбасска җибәрә. Иптәш Молотов анда Донбасс Губкомының секретаре итеп сайлана.

РКП(б) ның IX нчы съездында В. М. Молотов РКП(б) Үзәк Комитеты членлыгына кандидат итеп сайлана. 1920 нче елның ноябрендә ул—Украина КП(б) Үзәк Комитеты секретаре булып эшли.

Партиянең X нчы съездында В. М. Молотов РКП(б) Үзәк Комитетының члены итеп һәм шулай ук Үзәк Комитет Политбюросы членлыгына кандидат итеп сайлана. Биредә аның бөтен эше Ленин һәм Сталин белән турыдан-туры көндәлек элемтә тоту нигезендә бара.

Шушы вакыттан алып иптәш Молотов башкалада—Московада яши. Ул партиянең һәм Совет дәүләтенең барлык җитәкче эшендә катнаша.

1926 нчы елдан башлап иптәш Молотов ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы члены. 1927 нче елда ул Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы члены итеп, ә 1929 нчы елда СССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы члены итеп сайлана.

1928 нче елда иптәш Молотов ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре булып эшләү белән бергә, ВКП(б) ның Москва Комитеты секретаре итеп тә сайлана.

1930 нчы елның 19 нчы декабреннән башлап В. М. Молотов СССР Совнаркомы председателе итеп билгеләнә. Илебезне сталинчыл индустрияләштерүгә, Кызыл Армияне һәм Хәрби-Диңгез флотын югары класслы техника белән бик яхшы итеп коралландыруга, авыл хуҗалыгына социалистик реконструкция ясауга җитәкчелек итә.

1939 нчы елда В. М. Молотов СССР Совнаркомы предстдателе булу белән бер үк вакытта СССР ның Чит Ил Эшләре Халык комиссары итеп билгеләнә. Бөтен дөнья сугышы үсеп бара торган шартларда ул сталинчыл тынычлык политикасын тормышка ашыра һәм тарихи әһәмияте зур булган күп кенә мәсьәләләрне хәл итә.

Большевиклар партиясе, Ленин һәм Сталин иң җаваплы һәм иң катлаулы эшләрне иптәш Молотовка тапшырдылар. Югары белемле Марксист, зур культуралы һәм яхшы аңлы, кристал кебек чиста, какшамас пролетар революционер Вячеслав Михайлович һәрбер урында һәм һәрбер эштә партиябезгә дан китерде, аның уңышларын арттырды, масса белән элемтәсен ныгытты. Ул марксизмның-ленинизмның тантанасы өчен, партиянең генеральный юлы өчен эзлекле рәвештә көрәшә. Партиянең, хөкүмәтнең дошманнарын—троцкий-

чыларны, бухаринчыларны, зиновьевчыларны һәм буржуазиянең башка агентларын рәхимсез рәвештә җимерде һәм җимерә.

Бөтен совет халкы иптәш Молотовның нәтиҗәле эшен тирән ихтирам һәм чиксез мәхәббәт белән күзәтеп бара. СССР халыклары Вячеслав Михайловичка карата булган үзләренең кайнар мәхәббәтләрен аны СССР Верховный Советына, Союзный һәм Автономияле республикаларның Верховный Советларына бердәм рәвештә депутат итеп сайлауда бик ачык күрсәттеләр.

Лениннең турылыклы шәкерте һәм Сталинның якын көрәштәше булган иптәш Молотов совет балаларының да сөекле дусты. Ул берничә тапкыр пионерлар лагеренда, кояшлы „Артек“ та була. Балаларның ял итүләре белән таныша, бәхетле яшлекне тагы да бәхетлерәк итү өчен чаралар күрә. „Артек“та ул пионерлар белән бергә костер янында утыра, алар белән бергә җырлар җырлый, пионерларны үзенең дачасына һәм Москвага кунакка чакыра. Аларны аталарча сөя, иркәли, аларга киңәшләр бирә. Аның аталарча җылы кайгыртучанлыгын балалар һәр вакытта да сизәләр, беләләр.

Яшь чагында тырышып укыган Вячеслав Михайлович совет балаларының да аеруча тырышып укуларын тели. Светлана исемле кызына ул математиканы аңларга күп кенә ярдәм итә. „Ничек вакыт таба?“—дип гаҗәпләнүчеләр дә булыр.

Вакыт таба. Чөнки ул уку эшенә гаять зур әһәмият бирә. 1934 нче елның 21 нче июнендә, „Артек“та булганда, иптәш Молотов пионерларга карата болай диде:

— Сезгә, яхшы пионерларга, бөтен эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар карыйлар; сезгә барлык аңлы крестьяннәр һәм крестьян хатын-кызлар карыйлар. Пионерлар арасыннан укуны, эшне, техниканы, искусствоны яратучы—социализм төзүчеләр буыны үсә дип карыйлар алар.

Әгәр дә сез мускулларыгызны ныгытсагыз, уйнасагыз, җырласагыз һәм һәр төрле юнәлештә—уйлап табуга кадәр—үз талантларыгызны үстерсәгез, фәннәрне, әдәбиятны өйрәнсәгез,—һәм шуларның бөтенесен дә каннарыгызга, тамырларыгызга сеңдерсәгез,—сездән чын көрәшчеләр, нык большевиклар чыгар.

Яшәсен хезмәтне һәм укуны сөюче—уйный да, җырлый да, укый да белүче пионерлар!

Иптәш Молотовның бу алтын сүзләрен, балалар, бер вакытта да истән чыгармагыз. Сез дә, аның кебек үк, иң алдынгы укучы, коммунизмның җиңүе өчен батыр көрәшче булырга тырышыгыз!

В. М. Молотовка илле ел тулу уңае белән киң Советлар иленең барлык почмакларыннан, чит илләрнең пролетар оешмаларыннан йөрәктән чыккан җылы котлаулар ташкыны агыла. Миллионнарча совет балаларының тавышы да шуңа кушыла. Бу котлаулар иптәш Молотовка озак еллар буена сәламәтлек һәм Ватан өчен, халык бәхте өчен, коммунизмның тулы җиңүе өчен нәтиҗәле эш телиләр.

Бөек Сталинның якын көрәштәше һәм дусты—Вячеслав Михайлович Молотов озак еллар яшә!

Минем илле еллыгым уңае белән котлау һәм тәбрик җибәргән барлык оешмаларга, группаларга һәм кешеләргә чын күңелдән рәхмәт белдерәм.

В. МОЛОТОВ.

ДУС ҺӘМ ИПТӘШ

Ишек ачылды, һәм училище инспекторы класска керде. Ул үзе белән бергә ике яңа укучы да алып килгән. Мин партада бер үзем утыра идем. Яңа укучыларны минем янга утырттылар.

Тәнәфес вактында без бик тиз таныштык.

Вячик—минем күршемне шулай дип атыйлар иде—миңа үзенең Кукаркадан килүен сөйләде. Аның әтисен Нолинск шәһәренә эшкә күчергәннәр һәм алар бөтен семьяләре белән бирегә күчеп килгәннәр икән.

Бу яңа укучы миңа бик ошады, һәм без дуслаша башладык. Вячикне бөтен класс ярата иде. Ул безнең арада иң яхшы укучы булып, барлык фәннәрдән дә бишле билгеләре генә ала, укытучылар да аны еш кына мактыйлар.

Башка берәү аның урнында булса мактаныр, иптәшләренә бик өстән генә карар иде. Безнең белән бер класста укучы Витя Якимов әнә шундыйларның берсе иде инде. Бу малай яхшы укый һәм шуның белән бик мактана да! Әгәр дә берәр укучы начар билгесе алса, ул шатлана; ә инде аннан ярдәм сорасалар, ул иптәшне ялгыштырыр өчен нәрсә дә булса буташтыра торган иде.

Вячик исә бөтенләй башка иде. Ул ярдәм итүдән баш тартмады, һәркемгә булышты. Киңәш бирү, аңлату—аның өчен үзе бер шатлык. Ул бер вакытта да бер кемне дә алдамый. Балалар аны тагын менә шуның өчен дә яраталар иде. Аның сүзе бер вакытта да эштән аерылмады. Әйтте—эшләде.

Без иртән иртүк торып гөмбә җыярга барырга булабыз. Вячик йокыдан иң элек тора. Һәм башка балаларны уятырга дип аларның өйләренә бара:

— Әй, сез, йоклап ятасыз, ә үзегез иртән иртүк торырга вагдә бирдегез!

Укуда гына түгел, уенда да, күңел ачуда да ул иң алдынгы иде. Ул суда балык кебек йөзә, җәядән бик төз ата иде.

Кыш көне кардан крепость ясарга, шуны алып уйнарга бик ярата иде ул. Урамнан барлык балаларны җыя да „сугыш“ башлана. Кардан ясалган кечкенә шарлар сызгырып үтәләр. Еш кына шулай була иде: Вячик урныннан сикереп тора һәм үз отряды белән „дошман“ өстенә ташлана. Вячик ягы, һич үзгәрешсез, җиңүче булып кала.

Ул таза, нык малай булып үсте. Әгәр дә кем булса да берәү кечкенәләрне кыерсыта башласа, Вячик андыйларга юл куймый иде.

Менә шуңа күрә дә без бу яхшы, гади, чын дус иптәшебезне бик нык ярата идек. Вячик Нолинскидан Казанга укырга киткәндә безнең һәрберебезгә дә күңелсез булып калды.

Н. С. Чирков.

Киров өлкәсе, Молотовск шәһәре.

Кадерле кунак

Балалык вакытларым һәм иптәш Молотов белән беренче тапкыр очрашуларым бер дә исемнән чыкмыйлар. Ул вакытта Вячеслав Михайлович Казанда, беренче реальный училищенең соңгы классларында, укый иде. Ул, минем абыем Виктор Александрович Тихомирновның иптәше булганлыктан, еш кына аңарда була иде. Алар бергә укыйлар һәм кайбер вакытларда зур гына группа булып җыелалар, „Казан шәһәрендәге урта уку йортлары укучыларның революцион союзы“ членнары—социал-демократлар оешмасы белән элемтәдә булган кешеләр, булачак революционерлар иде алар.

Вячеслав иң яхшы укучы иде. Әнием аңардан энекәшем Германны гимназиягә хәзерләвен үтенде. Һәм ул җидди рәвештә эшкә кереште. Укытучы да, укучы да бер-берсе белән нык дуслаштылар. Кызганычка каршы, дәресне өзәргә туры килде. 1909 нчы елның апрелендә Вячеслав, Виктор һәм тагын кайбер иптәшләрне кулга алдылар.

Яхшылап хәтерли алмыйм, Молотов һәм аның иптәшләре кулга алынган елдамы, яки аннан бер ел элекме, кышкы каникул вактында „Снегурочка“ әкиятен без сәхнәгә куйдык. Бу пьесада бабай һәм әби укырга дип шәһәргә киткән улларының улы турында кайгыралар. Сәхнә артында скрипкада уйнау тавышы ишетелә... Викторның соравы буенча Вячеслав Михайлович безнең спектакльдә катнашты. Ул скрипкада уйнады. Ул начар уйнамый һәм үзенең скрипкасын бик ярата.

1916 нчы елның җәе минем хәтердә аеруча яхшы саклана. Яңгырлы, салкынча җәй. Безнең семья җәен Пустое Моркваш янындагы дачада яши иде. Июнь аенда без барыбыз да шул дачаның террасына җыелдык. Бер катлы кечкенә генә пароход килде. Бераздан соң террасага Вячеслав Михайлович килеп керде. Ул 1915 нче елда Иркутск губернасына өч елга сөргенгә җибәрелгән һәм шуннан качып килгән.

Вячеслав һәм Виктор көннәрен бергә үткәрделәр.

Бер вакыт алар миңа нинди генә эчтәлекле булса да хат язарга һәм аңа „Синең“ дип кул куярга тәкъдим иттеләр. Мин хат яздым, адресендә Кавказга диелгән иде, ахрысы. Минем хаттагы юллар арасына алар күренми торган кара белән үзләре дә хат яздылар. Минем бу кара турында бик беләсем килде килүен, ләкин аның турында сораштырырга батырчылык итә алмадым. Мин бу хатта бары тик Волганы бик тырышып-тырышып сурәтләвемне генә хәтерлим. „Хатны алучы мин язган юлларны бөтенләй укымасмы икәнни, кызыксынып кына булса да укымасмы икәнни?..“,—дип уйладым мин.

Вячеслав һәм Виктор һава яхшы булганда балык тоттылар. Волганың аръягында алар таллардан шалаш кордылар. Кайбер вакытларда берничә көн буена алар шунда булалар иде. Без аларга иртәнге һәм көндезге аш илтә идек.

Күп кенә вакыт үткәннән соң мин аларның Волга буйлап Казанга барууларын һәм анда эшчеләр арасында революцион эш алып баруларын белдем.

Кайбер вакытларда, яңгырлы көннәрдә, алар балык тоту җәтмәсен рәтлиләр. Мин шул вакытларда кычкырып китаплар укыдым. Вячеслав Михайлович Салтыков - Щедрин әсәрләрен аеруча ярата иде.

Бер вакыт мин Вячеслав Михайловичтан: большевиклар кемнәр алар һәм меньшевиклар кемнәр?—дип сорадым. Ул миңа аңлата башлады. Ләкин минем бу турыда аз белүемне һәм бик кыенлык белән генә аңлавымны сизеп алып, елмайды да ягымлы гына итеп болай диде:

— Сезгә әле моны аңлавы кыен, сез хәзер әле барсын да аңлый алмыйсыз, сезгә бик күп укырга кирәк әле.

Без Волганың аръягына чыктык, костер яктык, революцион җырлар җырладык. Без барыбыз да Вячеслав Михайловичның бик ягымлы тенор тавышлы икәнен белдек.

Вячеслав Михайлович бездән китәргә берничә көн генә калгач, бирегә тагын бер иптәш килде. Аны Всеволод дип йөрттеләр. Алар нәрсә турындадыр озак кына сөйләштеләр. Шуннан соң Вячеслав үзенең кечкенә генә чемоданын рәтләде. Моннан бер ай элек аны бирегә алып килгән кечкенә пароходка кадәр без барыбыз да бу кадерле кунагыбызны озата бардык.

О. Тихомирнова,

Казан Дәүләт Медицина Институтының биология кафедрасы ассистенты.



Казанда В. М. Молотов торган йорт.

В. М. Молотов „Артек“ пионерлары арасында (1934 нче елгы рәсем).
фото—**С. Лоскутов** (ТАСС фотоклишесе).

ОНТЫЛМАСЛЫК ОЧРАШУЛАР

1. Кояшлы „Артек“ та

1935 нче елның җәе минем күңелдә мәңге сакланыр. Мин ул елны пионерларның Бөтенсоюз лагере—„Артек“та ял иттем.

... Иртәнге сәгат 7 дә бөтен „Артек“ лагерын яңгыратып, сигнал уйнады. Без спорт площадкасына иртәнге зарядкага чыктык. Аю-даг тавы артыннан әкрен генә кояш күтәрелде. Һәм без аның җылы нурлары астында, иртәнге саф һавада, физкультура уйнадык. Озакламыйча без отряд-отряд булып линейкага тезелдек. Лагерьның көндәлек тормышын без һәр көн шулай башлап җибәрә идек.

Сафлар буйлап команда тавышы яңгырады:

— Смирно!..

Җаваплы вожатый:

— Бүген безгә кунак булып Вячеслав Михайлович Молотов килә,—диде. Без шатлыктан ни эшләргә дә белмәдек. Бөтен лагерь буйлап көчле „ура“ тавышы яңгырады. Минем янда басып торган якут пионеры үз телендә Молотов, Молотов дип нәрсәдер сөйләнде. Ул малай да минем кебек: „Тиз килерме икән Вячеслав Михайлович?“—дип үз-үзенә сөйләнгәндер. Чөнки безнең һәрберебез дә Вячеслав Михайловичны күрүне түземсезлек белән көтә иде. Һәрберебезнең дә күз карашы „Гурзов“ ял йортыннан безгә килә торган юлга төбәлгән. Шул юлдан Вячеслав Михайлович килергә тиеш.

Менә виноград куаклары арасыннан берничә автомобиль килеп чыкты. Без: „Вячеслав Михайлович, Вячеслав Михайлович!“—дип кычкырып, капкага таба йөгердек.

Автомобильләр площадкага килеп туктадылар. Иң алдагы машинадан өстенә чигүле ак күлмәк, аягына ботинка кигән уртача буйлы, көләч йөзле, яланбаш бер кеше чыкты. Бу кеше безнең иң зур, иң кадерле кунагыбыз—Вячеслав Михайлович Молотов. Без аны үзебез-

неӊ уртабызда калдырып, аӊа чәчәкләр бирдек, ә ул һаман елмая.

Вячеслав Михайлович безнеӊ белән бакчада йөрде, уеннарыбызны карап торды һәм безнеӊ белән рәсемгә төште. Фотограф рәсемгә төшү өчен бер агач янын күрсәтте. Бик матур урын, ләкин ул урында барлык пионерларны да рәсемгә алып булмый. Ә безнеӊ һәрберебезнеӊ дә Вячеслав Михайлович белән рәсемгә төшәсебез килә. Ул тирә-якка карады да:

— Әйдәгез, әнә теге ак йортныӊ баскычына утырып, төшәбез,—диде. Һәм без иптәш Молотов күрсәткән урында, аныӊ белән рәсемгә төштек. Мин ул рәсемне, Вячеслав Михайлович белән төшкән рәсемне, гомерем буена саклармын. Ул рәсем—минем өчен иӊ кадерле истәлек!

... Без көннеӊ үткәнен дә сизми калдык. Инде кояш „Артек“ ныӊ сул ягына сузылган таулар артына кереп яшеренде. Лагерьда утлар кабынды. Һәм без Вячеслав Михайлович белән бергәләп стадионга киттек. Стадионныӊ урта бер җирендә зур гына костер ягылган. Киӊ илебезнеӊ төрле почмакларыннан килгән, төрле милләт балалары үз телләрендә Вячеслав Михайловичны котладылар. Пионерларныӊ котлауларына җавап итеп, иптәш Молотов һаман елмайды, кулларын болгады һәм соӊыннан костер янына басып, безгә болай диде:

— Җылы каршы алуыгыз өчен рәхмәт. Яхшы ял итегез, һәм яхшыга, бик яхшыга укыгыз!

Вячеслав Михайловичныӊ бу сүзләрен мин бер вакытта да онытмам.

Элекке артекчы ***Әнвәр Фәйзуллин.***

Казан, Юридик институтның
1 нче курс студенты.

—★—

2. Москвада, Кремльдә

Москва.

1936 нчы елныӊ 17 нче сентябре.

Көзге җылы көн. Кызыл мәйданда, Спасск башнясе янында, пионерлар колоннасы тезелеп тора. Алар матрос формасындагы кием—пионерлар костюмы кигәннәр, кызыл галстук тагканнар, баш киемнәренә „Артек“ дип язылган.

Болар мактаулы „Артек“ лагереныӊ пионерлары.

Команда тавышы яӊгырый:

— Алга—шагом марш!

Бердәм, тигез атлап баручы бу пионерлар отряды Кремль капкасыннан керә.

***

Бу көнгә без алдан ук бик озак хәзерләндек.

— „Артек“ Москвага, иптәш Молотов янына бара!—Бу сүзләрне әйтү генә дә уенмыни?

Пионерларныӊ сөекле дусты—Совет хөкүмәте башлыгы белән лагерь инде берничә ел рәттән очрашты. Һәм бу тапкырда да гадәт бозылмады. Очрашу нинди урында бит әле! Кремльдә!

Бу хәбәрне ишетү белән лагерь бик нык дулкынлана, кайный. Костер мәйданында физкуьтурниклар репетиция ясыйлар. Югарыда, модельчеләр йортында, яш техниклар авиамодельләр хәзерлиләр. Биостанциядә, диӊгез янында, альбомнар һәм коллекцияләр җыялар...

Отрядлар иӊ яхшы дисциплина өчен, очрашуга иӊ яхшы хәзерләнү өчен ярыштылар.

Балалар автобусларга төялеп лагерьдан киткән чакта сөекле Артек җырыныӊ сүзләре аеруча көч белән яӊгырады:

— Мәӊге без истә тотарбыз
Артек, Артек!..

***

Менә без Совнаркомныӊ утырышлар залында. Өстәлләр янына тезелеп утырабыз. Барыбыз да дулкынлана. Ишеккә таба еш-еш карап алабыз. Чөнки иптәш Молотов шул ишектән безнеӊ янга керергә тиеш.

Менә ишек яныннадарак кына утыручы балаларныӊ алкышлау тавышлары һәм котлау авазлары кинәт яӊгырый башлый. Елмайган һәм кулын югары күтәргән хәлдә безне котлап, Вячеслав Михайлович килә. Без котлау сүзләрен

хор белән кычкырабыз. Һәркемнең йөзе—шатлыклы һәм тантаналы.

— Я, „Артек“ тагы тормышыгыз турында миңа сөйләгез әле,—ди Вячеслав Михайлович.

Биредә без, дөресен әйтергә кирәк, каушадык. Отрядның иң кыю ораторлары да аптырап калдылар. Утырабыз—барыбызга да уңайсыз, дулкынланабыз, сөйләшкәләп алабыз һәм бер-беребездән көләбез...

Вячеслав Михайлович безнең каушавыбызны аңлый. Ул ягымлы елмая һәм безне батырландыра.

Ә без „Докладчы урны“ дип язылган өстәл янына килеп басарга һаман да куркып торабыз әле.

— Я, сезнең арада иң батырыгыз кем?—ди Вячеслав Михайлович.

Бөтен зал:

— Барасби, Барасби!—дип кычкыра.

Ул—орденлы Барасби Хамгоков, ат өстендә йөрүче, кыю егет...

— Я, Барасби,—ди Молотов,—әйдә, чык, сөйлә.

Барасби безне уңайсыз хәлдән коткарды. Өстәл янына тиз генә килде дә „Артек“ та ничек яшәвебез турында: су коену, кояшта кызыну, сәяхәттә йөрү, төрле модельләрне һәм башкаларны ясау, уку турында...—барсы турында да сөйләде.

— Менә мин күрәм,—ди Вячеслав Михайлович,—сез ял да итә алмагансыз...

Без барыбыз да:

— Бу бит үзе ял!—дип кычкырабыз.

Вячеслав Михайлович безнең белән бергәләп көлә.

Иптәш Молотовка без үзебезнең бүләкләребезне—коллекцияләрне һәм альбомнарны тапшырдык. Авиамодельчеләр „Артек—Москва“ дигән аэропоезд моделе бүләк иттеләр.

— Артек җырларын җырлагыз әле,—ди Вячеслав Михайлович.

Без залны яңгыратырлык итеп җырладык! Һәм иптәш Молотов үзе дә кулын болгап, безнең җырга кушылды.

Без „Ватан турында җыр“, „Линкорда“, „Юбилей“ җырларын һәм ахырда үзебез иҗад иткән күңелле Артек җырларын җырладык. Анда бер куплет бар:

Артекка якын ук җирдә
Балкып тора Суук-Су...

Ә Суук-Су—„Артек“ янындагы ял йорты, дача ул. Лагерь Суук-Суны „Артек“ка кушу турында күптән үк хыяллана һәм иптәш Молотов та моны белә иде.

Без җыр җырладык. Молотов көлә. Без тагын җырлыйбыз:

„Артек“ка якын ук җирдә...

Иптәш Молотов урныннан тора да болай ди:

— Ярый, Суук-Суны сезгә бирергә кирәклеген мин сизәм.

Бик көчле алкышлар моңа җавап булдылар.

***

Иптәш Молотов безнең белән дусларча сөйләште. Ул безгә гүзәл лагерьда яхшы ял итеп, мәктәптәге эшкә тиешенчә керешергә кирәклек турында сөйләде.

— Сездән күп нәрсә соралыр, балалар,—ди ул. Һәм бөтен зал хөкүмәтебез җитәкчесенең бөек ышанычын һәм кайгыртуын акларга дип бердәм рәвештә вагдә бирә. Миңа якын гына утыручы корияле Пак та, шатлыкка күмелгән Мәмләкәт Нахангова да, кабардинлы кыю Барасби да һәм немец Губерт Лосто да—безнең артекчыларның дус семьясе членнары барсы да вагдә бирәләр.

Вакыт бик тиз үтә. Безгә китәргә кирәк—Вячеслав Михайловичны эш көтә. Саубуллашабыз. Сөеклебез Сталинга бездән сәлам тапшыруын сорыйбыз. Вячеслав Михайлович вагдә бирә һәм кулын дусларча безгә болгый.

Без, биредәге шатлыктан үз-үзебезне онытып, иптәш Молотов кереп барган ишеккә карап, рәхмәт сүзләре кычкырабыз. Саубуллашканда иң яхшы теләкләрне әйтәсе килә:

— Яшәсен иптәш Молотов!

— Яшәсен иптәш Сталин!

Һәм пионерларның сугышчан „ура“ тавышы бөтен залны яңгырата.

Бердәм, тигез колоннага тезелеп, без тагын Кремль буйлап барабыз. Безне Москваның шаулап торган урамнары каршылый. Кремльдәге очрашу турында озак-озак сөйләшәбез. Һәм анда үткән кадерле минутларны, барсын да бөтен тулылыгы белән хәтердә мәңге сакларга тырышабыз.

Элекке артекчы
Лев Безыменский.



РӘСЕМДӘ: СССР ның Памирдагы чик сакчылыгында.
Фото—**В. Шаховский.** (ТАСС фотоклишесе).

АЛМАЗ АБЫЙ

Кави Нәҗми

Безнең семья
Шактый зур:
Мин, Сәвия
Һәм Гөлнур,

Әнием дә
Әтием.
Әйтсәм инде
Әйтием:

Бабай белән
Әби бар.
Алмаз дигән
Абый бар.

Бабайның бар
Маэмае,
Абыйның бар
Бахбае.

Абый батыр
Командир,
Ул бит атлы
Кавалер.



Минем бабай—
Сунарчы.
Гөлнур апай
Һөнәрче.

Каи, кисә,
Тегә ул.
Әллә нәрсә
Чигә ул.

Әни—колхоз
Башында,
Былтыр көз
Уртасында
Аңар орден
Бирделәр:
„Үрнәк булдың—“
Диделәр.

Безнең матур
Сәвия
Инкубатор-
га ия.

Әби шунда
Булышчы.
Бездә барсы да
Эшче.

Минем әти—
Комбайнер.
Минем абый—
Командир!

—Үзең кем
соң?—
Дисезме.
Шуны да
Белмисезме?

Минем исмем
бит:
Йолдыз!
Мин әле бик
Нәни кыз.

Миңа бары
Алты яш,
Миңа тагы
Бар иптәш.

— Кем?—
дисезме.
Бабайның
Күрмисезме
Маэмаен?

Бер нидән дә
Курыкмый.
Бүредән дә
Курыкмый.

Ни эш кушсаң
Үти ул.
Уттан-судан
Үтә ул.

Ник ул алай?
Нилектән?
Абый шулай
Өйрәткән!

Чөнки ул бит—
Командир;
Бик кыю, бик
Батыр ир.

Монан,—диләр,—
Бик ерак
Финляндия
Дигән як...



Алмаз абый
Шунда, ди,
Чаңгыда, ди,
Шуган, ди.

Акларның арт
Сабагын
Укыткан, ди, ул
Тагын.

Җитсә әгәр
Яз ае,
Аның бит бар
„Бахбае“.

Рәсме дә бар
Альбомда:
Текә бер яр
Алдында,

Абый тора
Бик батыр,
Үрә бастырып
Атын.

Нигә алай?
Нилектән?
Абый шулай
Өйрәткән.

Чөнки ул бит
Кавалер!
Чөнки ул бит
Командир!

III, 40.

Балаларның Бөтенсоюз үзешчәнлек олимпиадасына хәзерләнәбез. РӘСЕМДӘ: Казан шәһәре, Киров районы 1 нче номерлы мәктәптә олимпиадага хәзерлек күрнешләреннән.

Фото—Б. Невзоров.

БЕЗНЕҢ БАЙРАК

Мин сокланып сиңа карыйм, байрак,
Ялкын кебек, янып торасың,
Корыч сафлар батыр атлаганда
Иң алдан син балкып барасың.

Подвалларда яшрен яткан чагың
Бүгенгедәй истә саклана,
Биеклектә хезер сине күреп
Йөрәкләребез чиксез шатлана.

Гөрләп үскән безнең киң Ватанга
Кояш кебек, нурың чәчәсең,
Зур көрәшләр үттек синең белән,
Мәңге-мәңге бездә яшәрсең.

Чит илдәге безнең туганнар
Коллык бавын өзер-туздырыр,
Ул җирләрне яктылыкка күмеп,
Синең алсу нурың сызылыр.

Салмак кына сине җилфердәтә
Таң атканда искән шаян җил,
Бердәм атлап синең нур астында
Зур җиңүгә бара туган ил.

Г. Камалов.

Кинопленка ФЗУ мәктәбе.

* * *

КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗЛЫЛАР

Илебезнең чиге буена
Кызыл йолдызлылар тезелгән.
Кылычлары үткен аларның,
Мылтыклары туры төзәлгән.
Бер адым да алар бирмәсләр
Ватанымның җирен ятларга.
Йөз сиксән өч миллион халкыбыз
Дошманнардан илне сакларлар.

Шамиль Латыйпов.

Чистай шәһәре.

ЧАҢГЫДА

Алсу шарфымны җилфердәтеп,
Шаян җилләр исеп үтәләр.
Кашларыма бәсләр төшерәләр,
Йөзләремне алма итәләр.
Мин йотылып сулыйм саф һаваны,
Карлы юлдан алга омтылам.
Менеп басам да мин биек тауга
Түбән таба коштай атылам.
Күкрәгемне киереп төшеп китәм,
Күперелеп мамык кар туза,
Үзенә күрә матур җырлар җырлап,
Йомшак карга чаңгым эз суза.

Д. Нәкыйп.

Молотов шәһәре.

* * *



Иваново шәһәрендәге пионерлар дворецында. РӘСЕМДӘ: дворецның кышкы бакчасындагы аквариум янында.
фото—**В. Шаровский.** (ТАСС фотоклишесе).

ӘНИЛӘР ҺӘМ АПАЛАР БӘЙРӘМЕ

Халыкара Коммунистик Хатын-кызлар көне—бөтен дөнья хезмәт ияләренең бәйрәме ул.

... Бу 1910 нчы елда булды. Күп кенә илләрнең вәкилләре—социалист хатын-кызлар Копенгаген шәһәрендә (Даниядә) үзләренең конференцияләренә җыелганнар иде. Ялкынлы революционерка Клара Циткин һәр ел саен Халыкара Коммунистик Хатын-кызлар Көне үткәрү турында тәкдим кертте. Конференция бу тәкдимне кабул итте һәм мондый көн итеп 8 нче мартны билгеләде.

Менә инде 30 ел буена дөньяның барлык илләрендә һәр ел саен хезмәт ияce хатын-кызлар бәйрәме үткәрелеп килә.

Казан шәһәре, Киров районы № 1 мәктәптә немец теле дәрсендә. РӘСЕМДӘ: укучы—отличница **Г. Парфеонова** һәм укытучы **О. Н. Шпаковская** **Фото—Б. Невзоров.**

Профессияләрне, фәннең, техниканың, искусствоның ул үзләштерә алмый торган тармагы юк. Очучы хатын-кыз, профессор хатын-кыз, дәүләт эшлеклесе хатын-кыз булу безнең илдә гаҗәп түгел. Совет халкының кызлары, гүзәл хатын-кызлар — Марина Раскова, Зинаида Троицкая, Паша Ангелина, Клавдия Сахарова, Роза Тамаркиналарның исме барлык кешегә дә билгеле. Алар үзләренең хезмәтләре белән Ватаныбызның данын арттырдылар.

Совет хатын-кызы —социалистик ватаныбызның ялкынлы патриоткасы. дошманнарга каршы көрәштә безнең әниләребез һәм апаларыбыз батырлык, йөрәклелек һәм геройлык үрнәкләре күрсәтәләр.

Безнең бәхетле илебездә яшәүчеләр бу көнне шатлык белән каршы алалар. Бары тик СССР да гына хатын-кызлар чын тулы хокук белән файдаланалар. Сталин Конституциясе аларга барсын да: хезмәткә, ялга, белем алуга хокуклар бирде. Авыр газаплы үткән көннәр кире кайтмаслык булып артта калдылар. Фабрикаларда да, заводларда да, колхозларда да, совхозларда да, гыйльми институтларда да, мәктәпләрдә дә—бар җирдә дә хатын-кызлар социалистик җәмгыятьнең актив төзүчеләре булып торалар.

Чит илләрдәге эшче һәм крестьян хатын-кызлар быелгы Халыкара Коммунистик Көнне икенче империалистик сугыш шартларында каршы алдылар. Алар политик хокуклардан мәхрум ителгәннәр; эшсезлеккә, ялангачлыкка, ачлыкка, хәерчелеккә дучар ителгәннәр. Һәм бу хатын-кызлар революцион пролетариат белән бергәләп үзләренең теләкләрен—империалистик сугышка каршы протестларын белдерәләр. Аларның күз карашы безгә—хатын-кызлар бәхетле һәм ирекле хәлдә социализм төзи торган илгә юнәлгән.



М. Сөндекле.

Г. Арсланов рәсемнәре

(Сюжеты русчадан)

Котырынып давыллана усал пурга,
Аюларны очырырдай булып дулый,
Кыш бабагыз искиткеч зур икән монда,
Болыт кебек сакалында җилләр улый.

Ул шундый зур, аның күкрәге тау кебек,
Башындагы бөдрә чәче томан кебек,
Бик күп еллар яшәгән ул бездән көлеп,
Аңа кеше якын килә алмаган әлек.

Бер ни дә юк боз кырында: урманнар да,
Болыннар да, чәчәкләр дә, сандугач та,
Сайрамыйлар монда моңлы тургайлар да,
Оя кормый монда матур карлыгач та.

Шундый баһадир булган ул ак котыпта
Кешеләр аны җиңү юлын белмәгәннәр,
Рәхәт, рәхәт яшәгән ул, патша кебек,
Җилләр аңа озын әкият сөйләгәннәр.

Әле дә ул бу баһадир камчы тотып
Басып тора җир шарының кыегында,
Язлар саен штыкланып туңган бозлар
Әзме дисең аның сакал-мыегында.

Кулындагы камчысының хикмәте шул:
Аның белән бер селтәсә төн урнаша,
Боз диңгездә айлар буе чыкмый кояш,
Һичбер нәрсә күреп булмый томан аша.

Һәм камчысын тагын да бер болгап куйса
Ай елмаеп сибә башлый якты нурын,
Ул күрсәтә шунда бөтен тирә-якны,
Кыш бабайның боз сараен, торган урнын.

Ул бер көнне сараенда мәҗлес җыйды,
Төрле яктан төрле кунак килде монда,
Мәҗлескә барын куйды, барын куйды,
Нинди генә хөрмәт кирәк сиңа монда.

Олыларча эндәште ул кунакларга:
„Менә хөрмәт, оялмагыз, сыйланыгыз,
Патша булсам да мин сезнең арагызда,
Тартынмагыз, үзегезчә кыйланыгыз“.

Кунакларны кыстап тора бөек хуҗа,
Зур бокалга салып бирә эчемлекне,
Мактанырга тотына ул кызып алгач,
Сөйләп китә кулындагы көчлелекне:
„Ничә еллар инде менә бу котыпта
Алмашынмый яшәп киләм патша булып,
Ничә-ничә баһадирлар тирә-яктан
Минем җиргә, байлыгыма сузды кулын.
Бик күп еллар көрәштем мин алар белән,
Гасырларча серләремне бирми килдем,
Кулым белән карабларын кысып ваттым,
Ә үзләрен балыкларга бүлеп бирдем“.
Аю кереп хәбәр итте зур сарайга:
„Бер ят тавыш килә, диде, җылы яктан“,
Кыш бабай да аптырап калды бу хәбәргә,
Кинәт эшкә куркып киттеләр кунаклар.
Гайрәтләнеп бойрык бирде кыш бабагыз:
„Бар, карап кер, кайсы илдән, нинди тавыш,
Яхшы тыңла, якындамы, еракта мы,
Куркакланып йөрмә монда, әйдә марш!“.
Аю борылып чыгып китте салмак басып,
Күп тә үтми тагын керде боз сарайга:
— „Лачын кошлар килә, диеп, СССР дан“
Калтыранып рапорт бирде кыш бабайга.
Кунаклар да кушылдылар карт аюга:
„Без ул илдә булган идек, йөргән идек,
Һәм без анда гаҗәп көчле лачын кошлар,
Бөркетләр һәм карлыгачлар күргән идек.
Ул кошларның канатлары алсу кызыл,
Ә түшләре көмеш белән уратылган,
Курыкмыйлар алар һичбер авырлыктан,
Шулар булыр, ул кошлардан була торган“.
Бойрык бирде гаскәренә кыш бабагыз:
Давылына, томанына, пургасына,
Себерергә тотынды җил ак карларны
Утырды да үзенең ак юргасына.

Кошлар оча зәңгәр күктә канат җәеп,
Давыллар һәм пургаларга кая монда,
Барыннан да өстә алар батыр кошлар,
Баһадирлар менә алмаган биек юлда.
Аксыл болыт каршы чыкты юлларына,
Ул болганды лачыннарның канатында:
„Кая болай очасыз сез ашыга-ашыга,
Әче үлем көтә сезне тау артында“.
Болыттан соң давыл килде улый-улый,
Һәм бераздан каршы чыкты аксыл томан,
Аксыл томан артыннан ул аллы-артлы
Пурга белән күтәрелде көчле буран.
Сугыш китте ике арада—гауга китте,
Давыл даулый, мотор шаулый, алга бара,
Кинәт шунда лачынннарның күзләренә
Кыш бабагыз торган сарай күренеп кала.

Кыш бабайның боз сарае өстендә дә
Лачыннарга юлны пурга бирми торды,
Сугыша торгач боз сарайның түбәсенә
Лачын кошлар бер-бер артлы килеп кунды.
„Салкын каршы алсаң да син— диде лачын,
Москвадан сәлам алып килдек сиңа,
Әлегә кадәр кеше үтмәгән таулар аша
Халыкларның җылысын алып килдек сиңа“.

Һәм бер көнне тагын күрде кыш бабагыз
Тирә-юндә лачын кошлар утырганын,
Аңа таба борылып кинәт пилотларның
Кулны кулга суга-суга кычкырганын:
„Кысыла төшәргә туры килер сиңа, бабай,
Күбәйделәр хәзер монда кунакларың“.
Озын кара сакаллысы аңа таба
Якын килде ике кулын артка салып.
Килде дә ул җылы перчаткасы белән
Көлә-көлә кыш бабайга кулын бирде:
— Минем сакал-мыек кара, синеке ак,
Шулай да без икебез бер төрле,—диде.
— Я әле икәү сөйләшик без синең белән:
Хәзер инде без яшәрбез бергә-бергә,
Шуның өчен безгә бүген ачык итеп,
Кирәк булыр аңлашырга, серләшергә.
Син белмисең бугай әле хезмәт данын
Сталинны, бөекләрдән бөек ирне,
Шушы көчле совет иле моторында
Әйләнергә кушты безгә бөтен җирне.
Киң сарайлар төзеләләр безнең илдә,
Бер-беренә тоташалар зур елгалар.
Төрле халык бердәм яши туганлашып,
Вак елгалар зур диңгезгә кушылалар.
Ул җибәрде безне монда юл ачарга,
Америкага иң туры юл сезнең аша,
Беләбез без, син кыш бабай, гасырларча
Булып тордың бу җирләрдә магрур патша.
Инде хәзер бир кулыңны, әйт сереңне,
Авырсынма боз сараең ватылса да,
Һәм курыкма бозларыңны ватып кереп,
Тау-тау булып аманатлар атылса да.
Данлы тормыш китерәбез котыпка без,
Нур, яктылык китерәбез котыпка без,
Курку белмәс бөркетләр һәм лачын кошлар
Зур эш белән ашкынабыз котыпка без.
Кинәт шунда кыш бабагыз йомшап китә
Бутап куя кулындагы камчы сабын,
Һәм шунда ук нурлар сибеп кояш чыга
Нурландырып боз сарайның тирә ягын.
Шулай да әле бик шикләнеп эш итә карт,
Лачыннарга кай чак кырын карап ала.
Кай чагында җавап бирми сораганда,
Сөйли дисәң ярты юлда туктап кала.

Тик лачыннар тараймыйлар кыш бабайдан,
Боздан сарай төзи алар үзләренә,
Карамыйлар кыш бабайның йомшак итеп
Сирәк-сирәк әйтеп куйган сүзләренә.
Сталиннан монда сәлам килеп тора,
Халыкларның җылы сулышы бәрелеп тора,
Лачыннарның шундый батыр эшләренә
Ерактагы ак аюлар әрнеп тора.
Буйсынмыйлар лачын кошлар ак котыпның
Гасырларча хөкем сөргән түрәсенә,
Кызыл байрак кадый алар боз сарайның
Карлар уйнап торган биек түбәсенә.

Тиз-тиз генә сөйләнсә дә бу әкиятләр,
Безнең тормыш алардан да тизрәк бара,
Давылларны үтә алган большевиклар,
Зәңгәр күктә болытлардан өстә оча.
Большевиклар кайту өчен җиналдылар,
Ә кыш бабай көлеп куйды шаян күздән:
„Сез китәсез, ә бит монда карлар белән
Күмеләчәк хәзер сезнең баскан эзләр“.
Тик ялгышты кыш бабагыз, лачын кошлар
Таулар аша килеп торды җылы яктан,
Америкага бер-бер артлы үтте алар,
Кыш бабайның сараена туктамастан.
Дулкынланды, кыш бабагыз ачуланды,
Карышырга бойрык бирде ак җилләргә:
„Нәрсә алар үтә башладылар әле
Сәлам бирми-нитми моннан чит җирләргә“.
Бер-бер артлы килде монда лачын кошлар,
Көрәштеләр ачы суык җилләр белән,
Ялгыз түгел бу батырлар ак котыпта,
Элемтә дә булды алар илләр белән.

Шуннан кыш карт өмет өзде, кул селтәде:
„Әйдә, диде, алай булса, бергә яшик,
Боз диңгезем, атауларым сезгә булсын,
Бергә торыйк, дөнья төзик, бергә эшлик“.
Карт аюны чакрып кертте дә кыш бабай:
— Бар, мәҗлескә лачыннарны чакыр,—диде,
Аю кебек салмак басып зур сарайга
Папанин һәм Кренкель дә килеп керде.
Озын бер речь сөйләмәкче кыш бабагыз,
Мыекларын-сакалларын сыйпап куйды.
Ак скәтер җәйгән өстәлгә таянып,
Сүз башлады, бөтен сарай тынып калды:
„Бик күп еллар монда патша булып тордым,
Шөһрәт таптым шушы каты кулым белән.
Күп баһадир батырларны кире бордым,
Җитәкчелек иттем котып юлы белән.
Инде бүген дөресен әйтим, җиңеләм мин,
Бөтен дөнья белә моны, яшереп булмас,
Бер-бер артлы очкан лачын кошлар кебек,
Большевиклар белән ахры ярышып булмас.



Большевиклар белән минем дуслашуым
Тарихларда зур бер әкият булып калыр,
Инде хәзер минем сарайның башында
Биш почмаклы кызыл йолдыз мәңге яныр".
Кыш бабайның бу сүзләрен тыңлаучылар
Кул чаптылар, кычкырдылар бердәм „ура",
Ә кыш бабай тиңсез биек гәүдә белән
Кул чапканны тау шикелле тыңлап тора.
Җавап рече сөйләмәкче иде Папанин,
Кинәт сарай яктырып китте нурлар белән,
Аю кереп хәбәр бирде кунакларга:
„Таралышыгыз, кунаклар, „Таймыр" килә".
Зәңгәр күкне яңгыратып лачын оча,
Ул төшәргә урын эзли сарай янга",
Аю кача бер якка ашыга-ашыга,
Исрек җилләр таралалар далаларга.
Һәм лачыннар җинаулашып киңәш итә:
Ни эшләргә кирәклеген кыш карт белән,
Шундый карарга киләләр лачын кошлар:
Бүләклиләр аны соры шлем белән.

Хәзер инде ерак котыпта кыш бабай
Төн йокламый постта тора айлап-айлап,
Юл күрсәтеп котып аша лачыннарга,
Тотып тора күккә сузып кызыл байрак.

Менә шулай бу әкиятме, яки чынмы?
Ни булса да анысы минем эшем түгел,
Кыш бабагыз шлем киеп төньягында
Халык өчен тырышып хезмәт итә бүген.





Калкукырда кар беткәч

(„Батыр исемле малай турында хикәяләр“ сериясеннән)

Мирсәй Әмир *П. Новичков рәсемнәре*

I.

Елның елында диярлек ашлык уңдырмый торган Калкукыр өстендә ашлык үстерү өчен кирәк булган төп шартларның берсе—кыш көнендә Калкукырны кар белән күмдерү иде. Бу шарт колхозчыларның тырышлыклары һәм пионерларның да ярдәме белән җиренә җиткерелде. Пионерлар тәгәрәтеп өйгән кар өемнәре ышыгына бик күп кар җыелды. Шулай итеп, гомергомергә кар төсе күрә алмыйча, кышлар буена туңып, шарт та-шорт ярылып ята торган Калкукыр өсте быел калын кар юрганы белән капланган иде. Шулай да, анда кар башка кырлардагыга караганда тизрәк эреде. Гадәттәгедән иртәрәк килгән 1933 нче ел язы Калкукыр өстендә тагын да иртәрәк башланды. Тугайлыктагы кырларда әле кар эреп бетәр-бетмәс хәлдә булса, Калкукыр өстендә кар күптән эреп беткән, күздән сөреп калдырылган каппкара җир өстеннән әкрен генә аксыл пар күтәрелә иде.

Ләкин иске авыл кырларын социализм кырларына әверелдерү юлында өзлексез көрәш алып барган большевиклар Калкукырда кар яткыру белән генә канәгатьләнергә ярамагынлыкны әйттеләр. Мондый калку урында иген уңдыру өчен,—диделәр алар,—кар суыннан алган дымны җилгә киптермәскә, орлыкны шыттыру өчен файдаланырга кирәк,—диделәр.—Моның өчен җирнең тәмам кибеп җитүен һәм башка кырларның да чәчәрлек хәлгә килүен көтеп тормаска, бүген үк Калкукырга чыгып, чәчә башларга кирәк,—диделәр.

Сүздән эшкә күчелде. Орлыклык бодай төялгән ящик арбаларның кыш буена ял итеп яткан авыр, нык тәгәрмәчләре язгы пычрак юлда бата-бата Калкукырга таба тәгәри башладылар.

II.

Язгы кояш кар астыннан чыккан юеш кара җирне ашыгып-ашыгып киптерә. Өзлексез исеп торган талгын җил аңар ярдәм итә. Сөргән җир кырында утырып имгәнмичә калган коры әрем, кырмавык, алабута, билчән, пәри арбасы кебек чүп үләннәр җылы кояштан да, талгын җилдән дә файдаланып калырга

тырышалар. Кар астыннан юешләнеп чыккан сабакларын җылы яз кояшының йомшак нурлары белән тиз генә кип-тереп алалар да, талгын җилгә ияреп, сөргән җир өстенә кереп китәләр. Анда алар кәсләргә бәрелгән саен кол-хоз җире өстенә үзләренең орлыкларын коеп калдыралар.

Әнә, бер „пәри арбасы" дип атала торган үсемлек әүмәкләнеп, сөргән җир өстенә кереп китте; әйбер урлап качкан карак малай төсле, кәсләрдән-кәсләргә сикереп чаба башлады. Ләкин аңа качып котылырга ирек бирмәделәр. Кепкасы җилгә очып калган кызыл чәчле малай аны куып җитеп, чабата-сы белән өстенә басты, аннан соң пәри арбасын уң кулына алып, югары күтәр-де һәм сул кулы белән маңгай тирен сөртеп, елмаеп куйды:

— Әһә, качып котылмакчы идеңме? Безнең җир өстенә үзеңнең чүп орлык-ларыңны коеп калдырмакчы идеңме? Юк, котыла алмассың,—диде ул. Аның тавышы, буена күрә, калынрак иде.— Әйдә әле, мин сине җылытыйм әле!

Малай аны сөргән җирдән читтә гөр-ләп янган зур учакка таба алып йө-герде. Йөзе кызыл сипкелләр белән чуарланган, яз көне булу сәбәпле бор-ны кубырчыкланган, ник гәүдәле, кы-зыл чәчле бу малай—безгә маглүм булган Батыргәрәй иде (билгеле, аңар әнисе генә Батыргәрәй дип дәшә, ә без инде аны Батыр дип кенә йөр-тәбез).

Тез тиңентен пычракка буялып, бата-бата бодай чәчеп йөрүче колхозчылар яныннан үтеп, учакка таба йөгергән вакытта Батырның башына бик күп уйлар кереп чыкты. Иң әлек ул чүп үләннәрен утый торган берәр машина уйлап табарга мөмкин түгелме икән, дигән сорауга җавап эзләде. Ул уйның очына чыга алмады, аның күңеле ап-ак сакаллы бабайга тартылды. Бабай, ар-тыннан куган төсле ашыгып, бодай чәчә. Җирнең пычраклыгына һәм чол-гау урап киелгән чабаталы аягының пычракка ябышуына аз гына да әһә-мият бирмәгәнсыман, җиңел итеп ат-лый. Башка чәчүчеләр орлыкны тубал-га тутырып чәчкән вакытта, бу бабай-ның алъяпкычтан гына чәчеп йөрүе Батырны бераз гаҗәпләндерде.

— Нигә, бабай, син алай алъяпкычы-ңа тутырып чәчәсең, сиңа тубал җит-мәдеме әллә?

— Юк, улым, җитмәгәннән түгел,— диде бабай,—мин бу алъяпкычка га-дәтләнгәнмен. Бер алъяпкыч орлы-гымның күпмегә җитәсен бик яхшы беләм мин. Чәчкән вакытта орлыкның күпмегә җитүен чамалый белмәсәң, ни-гә ярый ул аннары. Гектарга билгелән-гән орлык я җитмәс, я артып калыр.

— Бабай, болай кул белән чәчү ма-шина белән чәчүгә караганда файдасыз бит, нигә машина белән чәчмисез?

— Җир кибеп җитмәгән шул, улым, машина кертерлек түгел. Кибеп җиткә-нен көтсәң, бу Калкукырның нинди икәнен беләсең, өстәвенә ел да коры-рак килсә, уңыш бирми бит ул. Маши-наның яхшы икәнен бик беләбез. Пыч-рак җиргә чәчеп йөрү безнең өчен дә рәхәт түгел. Ашлыгы уңса бик рә-хәт булыр, дип өметләнәбез инде.

— Бабай, мондый кипмәгән җиргә чәчү өчен аерым машина уйлап чыга-рырга кирәк, әйе бит?

— Бик яхшы булыр иде, менә син, яш кеше, яхшылабрак укы да, уйлап тап!

— Мин үзем дә шуны уйлап йөри идем әле, бабай, беләсеңме, мин чүп үләннәрне утый торган машина ясарга да уйлап йөрим.

— Анысы бар инде аның, улым, мәшәкатьләнмә.

Батырның күзләре җанланып китте:

— Кайда бар соң ул, бабай? Алайса аны безнең колхозга да китертергә ки-рәк.

— Безнең колхозда да бар ул.

— Юкны сөйлисең, бабай, үзебезнең колхозда нинди машиналар барлыгын беләм лә мин.

— Триер барлыгын белмисеңмени?

Батыр бабайның нәрсә әйтергә теләгәнен бик тиз аңлап алды: Ә ә ә,—дип куйды ул,—орлыкны тазартып чәчсәң, чүп үләннәре булмый дип әйтергә тели икән бу бабай. Дөрес шул, чүпне үс-тереп, аннан соң утауга караганда, аның орлыгын ук җиргә төшермәү ях-шырак шул...

Мондый гади әйберне үзенең башта ук аңлый алмавыннан оялды Батыр, бабай янында артык сөйләшеп тә тор-мыйча, гөрләп янган учакларга таба йөгерүен дәвам иттерде.

Бернич урынга учаклар ягып, Калкукыр тирәсен әйләндергән чүп үләннәрнең корыган сабакларын яндыручы пионерлар барсы диярлек бер авыздан кычкырып, Батырны каршы алдылар.

— Әнә, үзе килә. Тиз бул, Батыр, сине көтәләр!

Кызу йөгерүдән Батыр еш-еш сулу ала иде.

— Менә бу пәри арбасы ашлык чәчкән җир эченә качкан иде, шуны тотып алып чыктым,—диде ул. Пәри арбасын гөрләп янган учак эченә ташлады. Пәри арбасы, тәне пешкәнгә чыдый алмагандай, ашыгып-ашыгып җыерылды, бөкләнгәләде дә шул ук минутта бер өлеше төтенгә, бер өлеше көлгә әйләнеп, юкка чыкты.

Батырны колхоз председателе Бәкер көтеп тора иде.

— Кил әле бирегә, Батыр, я әле, батырлыгыңны күрсәт әле, менә бу пакетны район җир бүлегенә илтеп тапшырып кайта алырсыңмы икән?

Район үзәгенә барып кайту Батырның иң яраткан эшләреннән берсе иде. Аның өстәвенә отряд җыелышында чыгарган карарлары бар: чәчү вактында пионерлар почтарлык ролен дә үтәргә тиешләр иде. Шуңар күрә дә председатель кушкан йомышны үтәргә Батыр рәхәтләнеп риза булды.

— Китер, хәзер илтеп җиткерәм,— диде ул.

Председатель аның ялгызын гына җибәрергә теләмәде:

— Ялгыз күңелсез булыр, үзең белән берәр иптәш тә ал,—диде ул һәм пионерларга борылып:—Кем Батыр белән бара?—диде.

Бер юлы берничә пионер ризалыкларын белдерделәр. Ләкин Батыр үзенә иптәшкә берәүне дә алырга теләмәде.

— Миңа иптәш кирәкми, бер үзем барам. Монда эшләгез, юк эш өчен ике кеше көчен туктатып торырга әллә...

— Ярый, үзең беләсең, ерак җир түгел,—диде председатель.—Анда безгә җибәрәсе кәгазьләре булса, аларны да алып кайтырсың, бар. Тик исеңдә тот, Батыр: Тәмле Елга аркылы чыкканда үзебезнең авыл күпере аркылы барма, аның читләренә су чыккан. Ераграк булса да, күрше авыл күпереннән урап бар. Кайтканда да шуннан кайтырсың!

Батыр, председательгә җавап биреп тормады, язулы кәгаздән ясап ябыштырылган зур конвертны чалбар кесәсенә тыкты да, зур козерокл җиңел кепкасын батырып киеп, авылга таба йөгерде.

III.

Батырның һәр эшне үз акылы белән генә эшләргә ярата торган гадәте бар. Бу гадәте аңар кайчакта файда итә, ә кайчакта зарар китерә. Исенә берәр нәрсә төшсә, исе китә дә куя: тукта әле, бу турыда миннән башка да уйлап караучылар бардыр дип уена да китермәстән, исенә төшкән әйберне эшләргә тотына. Я берәр эш коралы уйлап чыгарам дип азаплана ул, я булмаса берәр җәнлекнең каян килеп чыгуы турында хыяллана, берәр кызык вакыйга исенә төшә дә, шуны чын сүз төсле итеп сөйләп йөри башлый. Ә соңыннан ул уйлаган әйберләр башкалар тарафыннан күптән уйланган, тикшерелгән һәм хәл ителгән булып чыгалар да Батыр аптырап кала: „Мин моны алданрак белгән булсам, юкка баш ватмаган булыр идем“,—дип куя. Яңа бер нәрсә уйлап табу өчен тик бер үз башыңның гына җитмәвен, ул турыда башка уйлаучыларның да тәҗрибәләрен исәпкә алу кирәклеген аңлап җитә алмый әле Батыр. Шуның аркасында аңа еш-еш кына кыенлыкларга очрарга туры килә.

Бүген дә аны шул гадәте авыр хәлгә төшерде. Ул колхоз председателенең: „Тәмле Елга аркылы чыкканда үзебезнең авыл күпере аркылы барма“,—дигән сүзен тыңламады. Үзен бик акыллы кешегә исәпләп, председатель сүзләреннән көлеп куйган булды. Ул турыда аның уе болай иде: Бәкер абый минем нинди малай икәнлекне белеп җитми әле, мине куркак малай дип уйлый ул. Җә суга батып, үлеп-нитеп китәр, дип курка. Зурлар һәр вакытта шулай алар, үзләрен генә күп беләбез дип уйлыйлар. Күрә торып батып үләргә, әйтерсең, мин җүләр. Әйтерсең, Тәмле Елга күпере мин белми торган күпер. Шуннан куркып күрше авыл күперенә барып йөр имеш, шуның өчен километрдан артык җир ура... Шулай уйлады ул. Һәм, азгына да икеләнеп тормады, кулына тоткан озын таягына таянып сикерә-сикерә, үз авыллары тарафыннан салынган якындагы күпергә таба китте.

Бозы бүген генә кузгалган Тәмле Ел-

га шактый киң урынга җәелеп, чүпләр, бозлар белән болганып ага иде. Күпер турысында елганың үзәне тирән булу сәбәпле, су артык киң җәелмәгән булса да, председатель әйткәнчә, күперне ике як читләп ага, төрле агачлар, бозлар белән какшаган күпер җепкә тагылган төсле уртада тирбәлә иде. Күпер читеннән аккан су тирәнлек ягыннан куркыныч түгел иде түгелен, шулай да агымның бик каты булуы Батырның күңеленә шик салды. Бу суны кичеп чыгып маташырга ярамас, диде ул.

Ни эшләргә соң?

Батырның бер дә җиңеләсе, күпер читләп аккан шушы кечкенә сулар каршында чигенәсе килми. Ничек тә хәйләсен табып, шушы күпердән чыгарга кирәк. Һәрбер эшнең хәйләсен табарга уйлап күнеккән баш озак аптырамады, тиз әмәлен тапты:

— Нәрсәгә аптырап торам,—диде Батыр,—кулымда таягым бар ич!

Батыр таякка таянып бик биек һәм ерак сикерә алуы белән башка малайлардан аерыла иде. Бу урында ул үзенең шул һөнәрен кулланырга уйлады. Башта елгадан читкәрәк китте, аннан соң бөтен көченә йөгереп килеп, таягын елга читенә кадады һәм инерция законын файдаланып, таякка асылган гәүдәсен күпер өстенә ыргытты. Сикерүен бик оста сикерде, күпернең нак уртасына килеп төште. Тик күпер ышанычсыз булып чыкты. Бер-ике урыннан гына баганаларына тотынып, агым белән тарткалашып торган агач күпер, өстенә Батыр килеп төшү белән, сал шикелле булып, кузгалды да китте. Аның өстәвенә, Батырның кулындагы таягы су читендәге үзле балчыкка бик нык кадалган булып, шунда торып калды. Шулай итеп, безнең Батыр, таралырга торган күпер өстендә, бер нинди таяксыз-нисез, коры куллары белән чайкала-чайкала акты да китте.

IV

Председатель пакетны Батыр кулына биргәч, пионерлар янында озак тормады, чәчүчеләр янына китте. Һәрбер чәчүче янында булып, ничек чәчүләрен карады, андый-мондый уңайсызлыклар юкмы дип, сораштырып йөрде. Чәчүчеләр тирәсендә эшләр шома барганны күреп тынычлангач, орлык ташучы ар-



баларның берсенә утырып, авылга — орлык амбарлары янына кайтты. Анда куелган колхозчылар да эшкә чын күңелләре белән бирелеп, сокланырлык күңелле итеп эшлиләр иде. Бу күрнеш председательнең күңелен күтәрде. Аның кәефе яхшыланганнан-яхшылана бара иде. Батырга биреп район җир бүлегенә җибәргән язуны исенә төшереп, тагын да кәефләнә төште ул. Аның ул язуында чәчү эшенә керешү һәм беренче көн планының уңышлы үтәлеп баруы турында язылган иде. Язгач та, җибәримме икән, юкмы икән дип, бераз икеләнеп торган иде әле. Беренчедән, хәзер үк җибәрәм җибәрүен дә, кичкә кадәр ни буласын белеп бумый бит әле, план үтәлми калып, алдакчы булмаммы икән,—дип шикләнде. Икенчедән, әгәр кичкә кадәр көтсәм, бүген районга маглүмат бирә алмый калам, иртәгә кичкә генә бирергә туры килә. Ә райком секретаре бит бездән сводкаларны бер генә минутка да кичекми биреп торуны сорады, дип уйлады. Эшләрнең яхшы баруын күреп, планның үтәлеп чыгуында шиге калмагач, тотты да язды һәм Батырга биреп, район үзәгенә җибәрде. Хәзер инде ул планның үтәлүенә ышану гына түгел, аның арттырып үтәлүен дә өмет итә башлады.

Шундый яхшы кәеф белән тегендәмонда чабып йөреп, көннең үтеп киткәнен сизми дә калды ул. Кич була башлагач, ул Батыр турында уйлап алды: „Бу малай әле һаман кайтып җитмәдеме икән, әллә кайтып та миңа күренми йөриме икән?“

Шул уй белән ул Батырның әтисе янына килде:

— Нихәл, Нигмәтҗан абзый?

— Хәл яхшы, үзеңдә ни хәлләр?

— Безнең хәлләр бергә йөри инде хәзер. Сезнең хәл яхшы булса, минеке дә яхшы. Әле менә Батырны көтә идем, һаман кайтмадымы икән ул малай, әллә кайтып миңа күренми йөриме икән?

— Кая киткән иде соң ул?—дип сорады Нигмәтҗан абзый.

— Мин аны район үзәгенә җибәргән идем.

— Алаймыни? Бер үзе генә киттеме?

— Бер үзе генә китте, иптәш алмады.

— Белмәдем шул, кайттымы икән, юкмы икән,—диде Нигмаҗан абзый. Аның йөзенә бераз борчылу чырае чыкты.—Шулай да, Бәкер энем, язгы өзектә бала-чаганы ялгыз гына җибәрү кирәкмәс иде.

— Зарар юк, район юлы Батыр өчен яңа түгел бит инде. Ул үзе анда бару өчен атлыгып тора. Сыната торган малай түгел ул,—диде Бәкер. Тик шулай да, Нигмәтҗан абзыйның: „Язгы өзектә бала-чаганы ялгыз гына җибәрү кирәкмәс иде“,—дигән сүзе аны, әллә ничек, бераз шомландырып җибәргәндәй булды. Аның йөрәге тынычсызлана башлады. Ул бер нәрсә дә уйлап тормастан, Нигмәтҗан абзыйның өенә— Батырның әнисе янына китте. Ләкин ул Батырның өенә барып җитә алмады, Батырның әнисе Сания апа үзе аңар каршы очрады һәм председатель сорагангa кадәр Батыр турында үзе сүз ачты:



— Нихәл, Бәкер, синең яныңа бара идем әле. Батыр шунда, синең яныңда юкмы икән дип уйлаган идем.

— Нигә, Батырның өйгә кайтканы юкмыни әле?

— Кайтканы юк шул, иртүк чыгып киткән малай, нишләп йөри торгандыр, ашарга да кайтканы юк. Аны районга җибәргәнсең дигәннәр иде.

Председательнең йөрәге тагын да тынычсызлана төште, тик ул аны Сания апага сиздермәскә тырышты:

— Җибәргән идем шул, Сания апа, озаграк торды, анда юк-бар белән мавыгып киткәндер, малай кеше.

Председательнең тынычсызланганын Сания апа бик тиз сизеп алды һәм аның йөрәге кинәт чымырдап китте.

— Ай-һай, Бәкер,—диде ул калтыранган тавыш белән,—бер-бер хәл булмагае, ничек кайтыр ул бала, караңгы төшеп килә бит. Үзең беләсең, язгы өзектә бала-чаганы ялгыз йөртү ярыймыни?..

Председательнең тынычлыгы тәмам югалды. Тынычсызланганын яшерә дә алмый башлады:

— Шулаерак булды шул, Сания апа, син хафаланма, хәзер мин үзем атка атланып аңа каршы чыгам.

Председательнең бу сүзләре ана йөрәгендә туган шомны көчәйттеләр генә. Сания апа җылый ук башлады.

— Ай, балам, кайда гына булды икән, нинди генә бәләгә тап килде икән?..

Бәкер, хафаланган ананы тынычландырырга теләп, аңар өенә кайтырга киңәш бирде дә, үзе тиз генә атлар абзарына китте, һәм бер генә минут та уйланып тормастан, бер атны ияләп алды да, атланып район үзәгенә таба чапты. Бу минутта ул үзенең нинди зур ялгыш эшләвен сизгән иде инде. Пионерлар белән шундый җавапсыз эш итүенә күңеле борчыла иде аның:

— Ни булыр? Зур бәхетсезлекләр килеп чыкмаса гына ярар иде!..

(Дәвамы бар).

ПАРИЖ КОММУНАСЫ

Франция белән Пруссия арасында булган сугышның кырык дүртенче көнендә Наполеон III нең армиясе тар-мар ителде. Бу 1870 нче елның 2 нче сентябрендә Седан шәһәре янында булды.

Франция армиясенең җиңелүе турындагы хәбәр Парижга барып җиткәч, халык восстание ясый һәм республика иглан итә. Ләкин власть башына буржуазия урнаша.

Властьне кан эчкеч Тьер җитәкчелегендәге халык дошманнары үз кулларына алалар.

Пруссия гаскәрләре Париж янына ук килеп җитәләр. Ләкин Тьер хөкүмәте башкаланы саклау турында уйламый да.

1871 нче елның 18 нче мартына каршы төндә эшчеләр һәм ремесленниклар яңадан восстание оештыралар. Иртә белән Париж „Яшәсен Коммуна!“—дигән тавышларны ишетеп уяна.

Тьер хөкүмәте бәреп төшерелә. Министрлар Версальгә—корольләрнең Париж янындагы элекке ояларына—качалар.

Власть эшчеләр сыйнфы кулына күчә. Коммуна Советы сайлана һәм тарихта иң беренче тапкыр буларак, эшчеләр үзләренең дәүләтен төзи башлыйлар.

Ләкин коммунарлар беренче көннән үк бик күп ялгышлар ясадылар. Алар Тьер бандасын юк итү өчен Версальгә бармадылар. Алар Тьерга Париждан гаскәрләрен чыгарырга мөмкинлек бирделәр. Коммунарлар дошманнарга карата аяусыз булмадылар. Алар француз банкасындагы алтынны алмадылар.

* *
*

Париж коммунасы бары тик ике ай да ун көн генә яши алды. Ул беренче пролетар революциясе иде. Париж коммунасы совет властенең башлангычы булды.

Һәр елның 18 нче мартында Париж хезмәт ияләре кызыл байраклар белән Коммунарлар стенасы янына баралар. Алар үзләренең геройларын искә алалар. Коммунаның кызыл байрагына үзләренең турылыклы булулары турында демонстрация ясыйлар. Франция буржуазиясе Франциядәге коммунистларны каты эзәрлекли. Ләкин коммунарларлар буыны һәр төрле эзәрлекләүләрдән дә курыкмый. Коммунаның эше мәңгелек булуын алар яхшы беләләр. Хәзер ул заман түгел инде. Бөтен дөнья Коммунасы өчен көрәшүчеләрнең дөньяда терәге, ышанычы, маягы—бөек державасы — социалистик Советлар Союзы бар.





ТИМЕРЧЕЛӘР ЦЕХЫНДА

(Бер күренеш)

Г. Халик Садрый

БӨТЕН заводны карап узган Хәйдәр карт, тимерчеләр цехын да күздән үткәрергә уйлады. Җылы кояш нуры төшеп торган, зур тәрәзәле, иркен һавалы бу цех карарга күңелле иде... Ярсып-ярсып суккан пар чүкеченең эш процессы колхозчы Хәйдәрнең күңленә бик ошады булса кирәк!.. „Молодец, энекәшем, кулыңнан кинән“,—дип чүкечнең цилиндрына пар җибәреп торучы яш егетнең йөзенә карады һәм күңленнән генә: „Бу егет бик остадыр ахрысы“,—дип куйды. Тагын нәрсәдер әйтергә генә торганда, урта буйлы, көләч йөзле, күн алъяпкыч бәйләгән, киң күкрәкле тимерче, пешкән чиә кебек кызган тимерне чүкеч астына салып дөмбәсли башлагач, Хәйдәрнең сүзе киселде, тик ул авыз эченнән генә, чүкечнең сугуына ияреп; „Их, их!“ дип дәртләнде. Аның кулбашлары бераз тирбәнеп куйды, йөзендә тирән шатлык туды. Дөп-дөп итеп суккан чукеч астындагы тимернең формасы үзгәреп, минут эчендә таба хәленә килгәч, Хәйдәр, карт башын салмак кына чайкап елмайды да, кызуы да сүрелеп бетмәгән тимергә карап:

— Менә син хикмәт... Безнең машина кисәкләре бередә эшләнә икәнләбаса,—дип колхоздагы комбаенның моторын беркеткән рамкасын исенә төшерде... Чынлап та, бу пар чүкеченең хезмәте чиксез завыклы, ул һәр минут саен алтмыш-җитмеш кат удар ясап, төрле детальләрне кирәгенчә эшләп чыгара...

Монда ике кызык нәрсә бар: аның берсе, чүкеч астына салынган тимер калын булса, чүкеч югарыга күтәрелеп суга башлый, юка нәрсә эшләргә кирәк була икән, ул вакытта чүкечнең борны түбән төшеп, шул салынган нәрсәне корыч сандал белән ике арага кыса. Әгәр дә сиңа кәгаз калынлыгында бер нәрсә ясарга кирәк икән, ул аны бер дә иренмичә, бозмыйча ясап чыгара...

Икенче кызык нәрсә, яш егетнең осталыгында: ул кулына тоткан корыч сапны шул кадәр тиз, шул кадәр осталык белән күчерә, хәтта ул винтелләрне дә тиешле дәрәҗәдә генә ача. Шуңа күрә ул чүкеч әкрен дә, каты да итеп суга ала, тик моның өчен парны оста итеп бирә белү генә кирәк икән.

Пар чүкеченең бу эш процессын чын дәрт белән карап торган Хәйдәр карт:

— Әгәр дә нык кына өйрәнсәм, бу чүкечне мин дә суктыра алыр идем,—дип үз-үзенә сөйләнде һәм шуңа кызыксынып та куйды...

Чүкеч эштән туктап торган бер арада Хәйдәр карт яш егетнең янына килеп:

— Сез, улым, бу эшкә ничә ел өйрәндегез?—дип, сорау бирде.

Яш егет гаҗәпләнеп бераз елмайды. Аның бит өстендәге алма кебек кызарып торган урыннары батып киттеләр. Ул сөйкемле кара күзләре белән Хәйдәр картка төбәп карагач, терсәккә кадәр сызганган уң кулын саптан алмыйча гына, сөйләшә башлады:

— Мин, бабай, „Ирек“ колхозыннан. Әткәй элекке заманда батрак булган, үзем ФЗУ да укып өйрәндем... Исмем Кәрим була, ә сез, бабай, кайсы авылдан?

— Мин, улым, „Аккичү“ колхозыннан. Машина частьләре алырга килгән идем, эшегезне күреп чыгыйм дип кердем...

— Бик яхшы, бик яхшы, рәхмәт бабай,—дип яш егет тагын эшкә тотынды.

Бу сүзләрдән соң Хәйдәр карт ризалык күрсәтеп, китмәкче дә булган иде, ләкин тимерченең сигез йөз градуслы кызу пичтән бер зур тимерне алып чүкеч астына салганда, тимернең зәһәрле утлар чәчүе тагын туктатты. Ул яңадан кызыксынып карый башлады. Эшнең тизлегенә гаҗәпләнеп торды һәм чүкечнең ярсып-ярсып киткән вакытларында үз-үзен онытып, гәүдәсе белән биегән сыман, селкенеп тора башлады. Чүкеч туктагач ул:

—Да-а, мин сиңа әйтим. Бередә эшләр болай икән! Безнең колхозларга бу зур үрнәк булырлык, әйбәт эшли икән,—дип гаҗәпләнде.

Сүз арасында яш егет:

— Пар чүкеченең төрлесе була, бабай... Менә бу, безнең чүкеч, бер тонна көч белән суга,—дип, картның сорауларына тулы җавап бирергә тырышты. Кәримнең сүзләре картның күңленә завыклы булып тоелганмыдыр, ул кеткелдәп көлде дә:

— Бер тонна диген ә... Гаҗәп көчле икән! Әгәр дә аның астына кулыңны куйсаң, сытып чыгарыр бит, әкият... сизми дә калырсың мәйтәм, әйе...

— Юк, бабай!—диде Кәрим картның сүзен бүлеп,—ул болай куркынычлы нәрсә түгел, ничек суктыруга карый тагын. Куйган әйбернең калынлыгына карап парны бирә белсәң, һич зияны юк... Менә, бабай, әгәр дә сез теләсә гез, мин сезгә ял вактында бер тәҗрибә ясап күрсәтермен. Күз белән күргәч, үзегез дә ышанырсыз. Тиздән көндезге ял башланыр. Сез шул вакыт минем яныма килерсез.

Вакыт озак узмады, чүкеч астына куелган кызу тимерне тиз генә эшләп ташлагач, Кәрим тагын Хәйдәр карт янына килде.

— Менә капкачлы сәгат,—дип Кәрим кесәсеннән сәгатен алды да, Хәйдәр картка карады.

— Хуш... Шуннан соң?

— Сез, бабай, карап торыгыз, ә менә мин шушы сәгатне пар чүкече астына капкачын ачып куям, аннан соң пар җибәреп, чүкеч борны белән аның капкачын яптырырмын. Сәгатнең пияласына бер төрле дә зарар килмәс...

Хәйдәр карт күзләрен бер ачып, бер йомып алды да, кулбашларын сикертеп:

— Ай-һай, энем, булыр микән, алтмыш потлы гер белән бәргәндә нинди сәгат чыдасын ди. Ул бит челпәрәмә киләчәк,—дип, бераз уйланып торды. Кәрим үзенең сәгатен пар чүкече астына илткәндә генә, Хәйдәр җидди караш белән Кәримгә таба борылды да:

— Мә, энем! Минем сәгатне чүкеч астына куй!—дип өр яңа костюм кесәсенә тыгылып, көмеш сәгатен чыгарды һәм:

— Ватылса, ни булган, бодай күп әле, ничего, тагын сатып алырбыз,—дип сәгатне Кәримгә сузды. Ә үзенең йөрәге леп-леп итеп йомшак кына тибә иде.

— Куй, бабай... Чүкеч астына үз кулың белән куй! Ә капкачы ачыграк булып торсын.

Хәйдәр ике уйлап тормады, капкачы ачылган сәгатнең циферблаты өстендәге телләргә карап алды да, әзрәк елмайды. Шуннан соң, кызу омтылыш белән сәгатне пар чүкече астындагы корыч сандалның урта бер җиренә илтеп куйды да, аны җентекләп карый башлады.

Кәрим, үзенең яшлек таңында өйрәнгән иң беренче квалификациясенә нык ышанганга күрә, озак уйлап тормады, эшкә башлады. Сәгатнең калынлыгына, аның күләменә берничә кат карап алгач, кран сабын кинәт алга табан борып, кире үз урнына кайтарды... Ә Хәйдәр карт сәгатнең пияласы чәчрәмәсен дип күзләрен йомып ачарга да өлгермәде, гөрес итеп төшкән чүкеч борны, сәгатнең капкачын ябып, кире үз урнына менеп китте. Һәм югары менгәч, зур эш бетергән батыр сыман, бераз гына тирбәлеп торды. Ә сәгаттән өметен өзгән Хәйдәр, аның исән булуын, капкачның дөрес ябылуын һәм пияласының ватылмыйча калуын күргәч, кинәт шаркылдап көлеп җибәрде. Бөтен цехтагы эшчеләр хор белән бу көлүгә катнаштылар.

— Хәйран икән бу, әкият. Һөнәреңнән кинән, кулларың алтын икән, энем, яшә брат,—дип яш егетнең аркасыннан сөйде. Ул кояш нурлары белән чагылып торган сөйкемле станокка карап алга таба узганда стенага эленгән күрсәткеч тактасын күрде. Анда Кәримнең кичәге эш планын 260 процентка үтәвен күргәч, шатлыгын уртаклашмыйча булдыра алмады:

— Үсә бит безнең илнең яшьләре, һәр нәрсәгә өйрәнеп үсәләр. Элекке заманда атасы батрак булса, улы хәзер нинди зур машинага җитәкчелек итә!—диде ул.

Безнең календарь

Жюль Верн



Сәяхәт жанрында гыйлми-фантастик әсәрләр язучы Жюль Верн дөньяда иң күп укыла торга язучы. Аның кайбер әсәрләре Франциядә 50—60 шар мәртәбә басылганнар. Рус телендә басылган әсәрләренең гомуми тиражы 6—7 миллионнарга җитә. Жюль Вернның әсәрләре Европадагы барлык халыкларның телләренә, Азиядәге кытай, япон, гарәб һәм башка бик күп телләргә тәрҗемә ителгәннәр. Татар телендә Жюль Вернның „Серле утрау“ „80.000 километр су астында“, „Капитан Грант балалары“ исемле әсәрләре басылып чыкты.

Бөек кешеләрнең бик күбесе Жюль Вернның әсәрләрен яратканнар. Д. Менделеев аны „фән даһие“ дип атаган. Бөек язучы Л. Толстой аның турында болай дигән: „Жюль Вернның романнары бик гүзәл. Мин аларны үсеп җиткәч укыдым, шунда да алар үзләренең гүзәллекләре белән мине сокландырдылар. Укучыны интригалаучы, үзенә тартучы фабула төзүдә Жюль Верн гаҗәп оста. Ә сез аның турында Тургеневнең нинди соклану фикерләре әйтүен ишетсәгез иде! Жюль Вернга сокланган төсле, аның башка берәр кеше белән сокланганы минем хәтеремдә юк“.

Менә шундый бик күп әсәрләр язган Жюль Верн 1828 нче елның 8 нче февралендә Франциянең Нант шәһәрендә туган. Аның атасы юрист булган.

Жюль Верн яштән үк сәяхәтләр белән кызыксына башлаган.

Жюль Верн әкренләп төрле әдәби тәҗрибәләр ясаган. Танылган язучылар белән аралашып, каләмен шомарткан. Үзенә 34 яшь тулганда ул „Аэростатта биш атна“ исемле әсәрен язып Гетцель исемле издательгә китереп биргән. Гетцель үзе дә яхшы гына язучы булган. Жюль Вернның гыйлми-фантастик әсәрләр язарга оста булуын бик тиз күреп алган һәм аңа шушы такдимне ясаган: 20 ел буена шул ук жанрда елына ике том китап язып барырга. Жюль Верн риза булган һәм 20 ел гына түгел, 41 ел буена шул юнәлештә китаплар язган.

Австралиядә дә, Көньяк Америкада да, Азиядә дә, Арктикада да Жюль Верн булмаган. Су асты көймәсендә дә сәяхәт итмәгән. Алай булгач үзенең гаҗәп әсәрләре өчен ул материалны кайдан алган соң? Ул гыйлми әсәрләрдән бик нык файдаланган. Астрономиядән кирәкле белемнәрне ул Арагонның „Астрономия“ исемле китабыннан, географиядән кирәкле белемнәрне Элизе Реклюның „Гомуми география“ исемле китабыннан алган.

Бер хәбәрче Жюль Вернннан:

— Сез бик күп сәяхәт итәсездер?—дип сораган. Жюль Верн:

— Амьеннан китмәгәнемә озакламыйча илле ел була. Дөнья хәзер шул кадәр өйрәнелгән ки, бөтен нәрсәне китаплардан белеп була,—дип җавап биргән.

— Алай булгач сезгә караб нигә?—дип сораган хәбәрче.

Жюль Верн:

— Әйдәгез!—дигән һәм ул кунакны диңгез кырыена алып киткән.

Кечкенә бер яхта дулкыннар өстендә селкенеп тора. Шул яхтага килеп җиткәч, Жюль Верн кунакка болай дип сөйләгән:

— Менә минем „Сант—Мишель“ исемле яхтам. Аның каютасында сәяхәт китаплары, карталар, диңгез турында белешмә китаплар ята. Менә минем Сандр һәм Альфонс исемле ике матросым. Алар белән без кай вакыт Гаврга кадәр барабыз.

— Ни өчен соң сез ераграк сәяхәтләргә китмисез?

Жюль Верн:

— Ахрысы мин үземнең язу өстәлемнән ерак китәргә куркка торганмындыр. Һәр көн иртәнге сәгат биштә мин язу өстәле янына утырам,—дип җавап кайтарган.

Жюль Вернның китаплары ул вакыттагы фәннең, техниканың уңышын бик дөрес чагылдыралар. Жюль Вернның китапларында фәннең, техниканың киләчәктәге уңышлары да бик оста бирелгәннәр. Мәсәлән, ул электрик белән эшли торган су асты көймәсе ясарга мөмкин икәнлеген күрсәткән. Хәзер аның кебек су асты көймәләре инде бар. Жюль Вернның геройлары су асты көймәсе белән боз диңгезенә баралар. Аның кебек сәяхәтләрне Симон Лэйк, Данненкофер, Вилкинс кебек кешеләр әле яңа гына тормышка ашырырга җыеналар. Менә шуларга карап без Жюль Вернне гади язучы түгел, ә „фән шагыйре“ дип атый алабыз.

Үзенең гыйлми фантастик әсәрләрен язуны Жюль Верн үлгәнчегә кадәр дәвам иттерган. Ул тәртипле рәвештә ел саен икешәр том романнар чыгарып барган. 1895 нче елда аның сул күзе сукырайган. Шулай да ул үзенең әдәби эшен туктатмаган. 1900 нче елда ул бөтенләй сукыр булып калган. Шуннан соң ул үзенең әсәрләрен хатынына әйтеп торып яздырган. 77 яшьтә Жюль Верн шикәр авыруы белән авырый башлап, 1905 нче елның 24 нче мартында үлгән.

Хәмит Кави.

Җаваплы редактор
Г. ХӘБИБУЛЛИН.

Ответств. редактор
Г. ХАБИБУЛЛИН.

Заказ № 1274. 2 табак. Табакта 70.700 знак. Главлит вәкиле № 204. Производствога бирелде 7/III—40 ел. Басарга кул куелды 3/IV—40 ел. Тираж 8075. Кәгаз форматы 70×108.

Александров исемендәге типография. Казан Бауман урамы, 19. 1940 ел.

Күңелле ял

ГЕОГРАФИК ДОМИНО

„Домино" уены борынгы грекларга ук билгеле булган. Тора-бара алар бу уенны онытканнар. Бары тик XVI нчы йөздә генә Көнбатыш Европада аның турында искә төшергәннәр.

Домино—кызыксындыручан уен. Биредә исәпли белү, яхшы хәтер һәм тиз төшенү таләп ителә.

Гади доминоны сез барыгыз да беләсез. Ә менә географик домино турында күпләр белми әле. Шуны да әйтергә кирәк, аны ясау бик җиңел. Катыргадан яки калын кәгаздән 3×10 сантиметр зурлыгында 37 (артыгырак та мөмкин) карточка кисегез.

Һәрбер карточканың йөз ягын урталай бүлегез һәм һәрбер кисәккә рәсемнәр ясагыз. Аңа материк, елга, шәһәр, тау һәм башка шуңа охшашлы рәсемнәр ясарга була. Сезгә билгеле булганынча, елга буена урнашкан шәһәрләр дә бар: мәсәлән, Сена елгасы буенда Париж, ә Темза елгасы буенда Лондон тора һәм башкалар. Уен вактында, килешү буенча, шәһәрләр рәсме янына шул ук шәһәр янындагы елганың рәсме төшерелгән карточкаларны да куярга мөмкин.

Уенның тәртибе гади доминодагы кебек үк. Карточкалар рәсемнәре күренмәслек итеп, капланган хәлдә, өстәлгә таратылалар һәм бер-берсе белән аралаштырылалар. Шуннан соң карточкалар уенда катнашучыларга өләшенәләр. Һәркемнең бурычы—карточкаларны мөмкин кадәр тизрәк рәвештә (уен тәртибе буенча) өстәлгә куеп бетерү. Кулында карточкалар калган кеше һәрбер рәсем өчен 10 ар очко оттыра. Шуңа күрә бер карточка 20 очкога кадәр оттырыш бирә ала.

Ягез, балалар, яңа уенны башлап җибәрик!

Метаграмма

„К" дән башлап укысагыз,
җир ашларга китә.
„Г" дән башлап укысагыз,
чәчәк атып үсә.

М. Гәрәев.
Казан шәһәре.

Халык табышмаклары

Ак сыер китәр, кара сыер ятып калыр.
Кечкенә генә келәттә 32 капчык.
Күрергә күркәм, тотарга куркам.

Язып алучы **М. Фатыйхов.**
Чкалов өлкәсе.

СИН БЕЛӘСЕҢМЕ?

ҖИРГӘ НИЧӘ ЯШЬ?

Җиргә ничә яшь? Аны нинди билгеләр буенча белеп була?

Бәхеткә каршы, табигатьтә махсус „геологик сәгатьләр" бар. Бу сәгатьләр Җир яралганнан соң ук хәрәкәт итә башлаганнар. Нак инде менә шулар безнең сорауларга җавап бирәләр. Нинди сәгатьләр соң алар?

Уран дигән металл бар. Вакыт үтү белән ул ике төрле химик элементка: кургашын һәм гелий элементларына таркала. Бу таркалуның законы галимнәргә билгеле. Шуңа күрә алар берничә ел вакыт үтү белән бер килограмм ураннан ничә грамм кургашын белән гелий хасил буласын беләләр. Һәм киресенчә: кайда да булса уран белән кургашынның бергә ятуын күреп, уранның кайчан таркала башлавын да белергә мөмкин.

Башта үзләрендә уран булып, аннан кургашынга әйләнгән тау токымнарын галимнәр тикшергәннәр. Бу тикшеренүләр шуны күрсәткәннәр: уранның Җирдә таркала башлавына 1,4 миллиард елдан ким булмаган һәм 3,4 миллиард елдан артык булмаган вакыт үткән. Моны анык рәвештә билгеләргә мөмкин түгел. Менә шуңа күрә дә, якынча саннар белән хисаплап, моны 2 миллиард ел дип йөртәләр. Галимнәр Җирнең яшен шулай дип билгелиләр.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

„ПИОНЕР КАЛЯМЕ“

ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ЖУРНАЛ ПИОНЕРОВ И ШКОЛЬНИКОВ
ОРГАН ОБКОМА ВЛКСМ И НАРКОМПРОСА ТАССР.